Сөт арта – акча кими

Шәхси хуҗалыкларда тир түгеп ризык табучыларның кәефләре тагын да ныграк төшәргә охшап тора, чөнки июнь башыннан сөт сатып алу бәяләре тагын арзаерга мөмкин.

4 БИТ



Татарстан кызына уникаль протезлар куелды

Шушы көннәрдә Азнакай кызы Гөлназ Насыйбуллинага Мәскәү табиблары уникаль протез куйдылар. Бер ел дәвамында сул кулы белән генә эшләргә мәҗбүр булган туташ өчен моннан соң яңа тормыш башлана.

12 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 25.05.2017 | № 55 (5817) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ИЛГӘ ЭШЧЕЛӘР КИРӘК

Казанның иң яхшы урта һөнәри белем бирә торган уку йортлары исемлеге

Инде ничәнче ел ил һәм республика җитәкчелеге эшче һөнәрләргә ихтыяҗ булу, аларның дәрәҗәсен күтәрү турында сөйли. Безнең укучыларыбыз арасында да юллар чатында торучы кешеләр барлыгын һәм «Мин дә мулла, син дә мулла, атка печән кем сала?» дигән гыйбарәне дә истә тотып, без Казанның иң яхшы урта һөнәри белем бирә торган уку йортларын барладык.

10-11 БИТ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

УРАЗА ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

13 БИТ

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА КИҢӘШЛӘР

9 БИТ

РЕСПУБЛИКАДА

САБА

Саба шашкачылары Россия буенча ярышларда өченче урынны алган. Волгоград шәһәрендә инвалидлар арасында шахмат-шашка буенча үткәрелгән Россия беренчелегендә 26 төбәктән 74 кеше көч сынашкан. Татарстан командасы өчен Сабадан Азат Әхмәтов, Хәмит Вәгыйзов, Балтачтан Чулпан Габделганиева чыгыш ясаган.

АПАС

Апаста күчмә кино күрсәтү хезмәте эшли. Район мәдәният йорты каршында эшләп килүче кино күрсәтү хезмәте киномеханигы Динар Мотыйгуллин һәр авылга баруны максат итеп куйган. Һәр атнаның җомга көнендә район мәдәният йортында фильм карарга мөмкин булачак. Авылларда график буенча куелачак.

ӘГЕРҖЕ

Әгерҗедә тиздән яңа Балалар иҗат йорты һәм физкультура-сәламәтләндерү комплексы барлыкка киләчәк. Төзүчеләр аларны өч айдан тапшырырга вәгъдә итә.

ӘЛМӘТ

31 яшьлек Әлмәт кешесе бушлай белдерүләр сайтыннан үзенең машинасына кирәкле запчастьлар тапкан. Телефон буенча шалтыраткач, трубканың теге башында башта кирәкле сумманы – 125 мең сумны түләвен таләп иткәннәр. Ир акчаны түләгәч, шалтыратып караса, аңа җавап бирүче булмаган.

КУКМАРА

Кукмарада район мөхтәсибе сайлаулары булды. Район мөхтәсибе итеп Рәдиф хәзрәт Тимергалиев сайланды. Шул ук көнне мәдрәсәдә чыгарылыш кичәсе дә узды. 78 чыгарылыш шәкертенә дипломнар тапшырылды.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды

БАШЛАНА!

Иртәгә Бердәм дәүләт имтиханы бирү кампаниясе башлана. Беренче имтиханны укучылар инглиз теленнән тапшырачаклар. Соңгы имтихан исә 1 июльгә билгеләнгән.

edumsko.ru

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе Гөлнара Габдрахманова сүзләренчә, БДИ тапшыручыларның саны – 14 946 кеше. Моннан тыш, 35 196 IX сыйныф укучысы төп дәүләт имтиханы тапшырачак. Сәламәтлеге белән проблемалар булган 341 бала имтиханны аерым шартларда (өйдә яки махсус әзерләнгән пунктларда) бирә алачак. Башкалардан аермалы буларак, алар өчен имтихан вакыты тагын 1,5 сәгатькә озынайтыла.

Бердәм дәүләт имтиханнарын тапшыру кампаниясендә 19 меңнән артык кеше катнаша. Быел да имтихан бирүчеләр, металл рамкалар аша узып, имтихан тапшыру кабинетларына керәчәк. Аларны онлайн рәвештә күзәтү өчен кабинетлар 100 процентка җиһазландырылган. Һәр кабинетта икешәр камера торачак. Быелгы имтиханнарның тагын бер яңалыгы – IX сыйныфтан соң имтихан тапшыручыларны педагогия көллиятләрендә белем алучылар күзәтәчәк. Имтихан кампаниясен уздыру министрлыкка 60 миллион сумга төшә.

– Әгәр бала имтиханга соңга калып килә икән, без аны имтихан тапшыру кабинетына кертәбез. Ләкин имтихан бирү вакыты аның өчен озынайтылмый, – дип белдерде Гөлнара Габдрахманова.

Быел чыгарылыш сыйныф укучылары 14 фәннән Бердәм дәүләт имтиханы тапшыра алачак. Шуларның икесе – рус теле һәм математика мәҗбүри, калган фәннәрне исә чыгарылыш сыйныф укучысы үзе сайлап ала. Шунысы да мәгълүм, укучы үзе күпме теләсә, шул кадәр имтихан тапшырырга хокуклы. Ләкин аттестат алу өчен дүрттән дә кимрәк имтихан бирергә ярамый.

– Узган еллардагы кебек үк, иң популяр имтиханнар исемлегендә – җәмгыять белеме, физика, биология һәм химия фәннәре, – ди мәгариф һәм фән министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов.

Аның сүзләренчә, соңгы елларда Бердәм дәүләт имтиханының нәтиҗәсеннән канәгать булмыйча, апелляция бирүчеләр саны кими.

– Апелляция, имтиханның нәтиҗәләре билгеле булганнан соң, ике көн эчендә бирелергә мөмкин, – диде министр урынбасары.

Быел Татарстанда БДИ тапшырырга теләүчеләр арасында 40 яшьлек кеше дә бар. Имтиханны ул берничә фәннән һәм югары уку йортына керү максаты белән бирергә теләк белдергән.

Айгөл Хәйруллина, «Болгар» радиосы алып баручысы:

– *Улым Булат быел мәктәпне тәмамлый. Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлек сентябрьдә үк башланды. Репетиторлар ялламадык, үз көчебезгә ышанабыз. Имтихан алдыннан була торган дулкынлану бар, әлбәттә. Барысын да яхшы гына бирер дип ышанам.*

Габдулла Җиһаншин, чыгарылыш сыйныф укучысы:

– *Узган елның языннан алып бер ел буе өстәмә уку курсларына йөрдем. Рус теле белән математикадан белемнәремне ныгыттым. Имтиханнар алдыннан металл рамкалар аша уздыруларыннан, камералар күзәтеп торуыннан курыкмыйм. Мин аларны шулай булырга тиеш дип кенә кабул итәм, игътибар итмәскә тырышам.*

Нурзия Хәсәнова, математика укытучысы:

– *Хәзер балалар БДИны үз иттеләр инде. Математика фәнен дә төп һәм профиль юнәлешенә бүлеп җиңеләйттеләр. Бөтен кеше дә математик булып бетә алмый бит инде. Кайвакыт, авылда БДИга сирәк әзерлиләр дип, кырын сүзләр ишетергә туры килә авыл укытучысына. Бу алай түгел. Шәһәрдә балаларның төрле репетиторларга йөрергә, югары уку йорты каршында уздырылган дәресләрдә белем алу мөмкинлеге бар. Ә авыл җирендә барысы да укытучы җилкәсенә генә төшеп кала. Күпме булдыра ала, күпме көченнән килә, укытучы балаларны шуның кадәр әзерләргә тырыша. Минем эшләү тәҗрибәмдә БДИ тапшыра алмаган, начар билге алган бер генә укучы да булмады.*

Шәһәр кәефе

ОТАРИ МАРТИРОСЯН,
музыкант:

– Армениянең Ереван шәһәреннән 1976 елда килгән идем. Казанны ошаттым да шушында төпләнеп калдым. Язмыш галәмәтедер. Казан искиткеч үсте. Ләкин чисталык мәсьәләсендә таләп йомшаграк әле. Халыкның тормыш дәрәҗәсе тагын да яхшырсын иде. Татарстанда милләтләр арасындагы дуслык мәңге саклансын, тынычлыкта яшәү рәхәт бит. Музыка коралларында уйнарга, рәсем ясарга яратам.

ИСЛАМИЯ ГАЛИМОВА,
кибетче:

– Башкортстанда туып-үстем. Уфада яшьлелек күбрәк, Казанда агачлар утырту эшләре туктап калмасын иде. Җырларга яратам. Әти белән әнине диңгезгә ял итәргә алып барсаң иде дип хыялланам. Казан читендә кечкенә генә булса да үз өебезне төзеп, шунда бакчада казынып яшәсәң иде, дип, ирем Айдар белән әллә ниләр хыялланабыз әле тагын. Аллага шөкер, исән-сау эшләп йөрибез. Өлкәннәр әйтмешли, булганына канәгать.

ГҮЗӘЛ ЗӘЙНУЛЛИНА,
укытучы:

– Казан дәүләт университетын тәмамладым. Тумышым белән мин Оренбургтан. Киров районындагы 81нче мәктәптә «Эвакогоспиталь 36-46» музееи җитәклим. Сугыш елларында бу мәктәп госпиталь булган. Мәктәбебез каһарман танкист Виктор Григорьев исемен йөртә. Бөек Ватан сугышы каһарманы Виктор Григорьев бюстын мәктәп каршына да куйдырасы иде. Шушы мәсьәләне хәл итәргә теләүчеләр табылыр бәлки.

РОЗА ЮСУПОВА,
парикмахер:

– Казан тарихы белән кызыксынам. Тарихны күбрәк өйрәнгән саен, Казанның европалаша баруына үкенү-кызгану хисе көчәя. Чит ил туристлары безгә Европа дәрәҗәсендәге биналарны түгел, ә тарихи урыннарны карарга килә лабаса. Тарихи биналар саклансын, торгызылсын иде. Татарстандагы тарихи урыннарны фоторәсемгә төшерер өчен махсус сәфәргә кузгалырга ниятлим бу җәйдә.

ИЛДАР ВӘЛИУЛЛОВ,
хезмәткәр:

– Чүпрәле районыннан үзем, Казанда 1992 елдан. Шәһәр кешесе булдык, дип, туган якны ташлаган юк. Авылда туганнарны күреп, кулга балта, көрәк тотып эшләп килү үзе бер сихәт бит ул. Киров, Мәскәү һәм Авиатөзелеш районнарында Казаннан чыгу-керү юлларын киңәйтеп төзесеннәр иде. Үзем өчен түгел, хәзер инде күбрәк: «Балалар яхшы гына укысыннар, тормышта үз урыннарын тапсыннар иде», – дип телим.

Республика ифтары Теннис академиясендә узачак

Республика ифтары быел 15 июньдә Теннис академиясендә үтәчәк. Татарстан Мөселманнары диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге җитәкчесе Айгөл Биктимерова безгә хәбәр иткәнчә, тиздән «Казан-Арена» стадионында Конфедерация кубогы уеннары уздырылу сәбәпле, быел ифтар мәҗлесен анда үткәреп булмый.

– Быелгы ифтарда, узган елдагыча, 10 мең кеше катнашыр дип көтелә. Аларга 700 волонтер хезмәт күрсәтәчәк. Шуның кадәр волонтер килергә теләк белдерде. Узган елгы тәҗрибәдән чыгып әйткәндә, моның кадәр кеше белән бу зур эшне, Аллаһ кушып, башкарып чыгачакбыз. Ифтарга күп балалы гаиләләр, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр, ятим балалар да чакырыла, – дип сөйләде ул.

Ифтар мәҗлесен Диния нәзарәте, Мөселман эшкуарлары ассоциациясе, «Казан-Арена» стадионы дирекциясе оештыра. Мәҗлестә дин әһелләренең вәгазьләрен, мөнәҗәтләр ишетеп булачак, бөтен җәмәгать бергәләшеп намаз укыячак.

Сүз уңаеннан, Татарстанда Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрен билгеләп үтү көннәре тәгаенләнде. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Указы белән, Ураза гаете 2017 елның 25 июнендә бәйрәм ителәчәк. Корбан бәйрәмен 1 сентябрьдә билгеләп үтәчәкбез. 1 сентябрь ял көне булачак.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

САН

*Быел Татарстанда **218** мең баланың җәйге ялы оештырылачак.*

ТОП – 3

РОССИЯ Президенты Владимир Путин Татарстанның Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән Казан һәм Татарстан митрополиты Феофанны «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләде.

АГЫМДАГЫ ел ахырына Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы опека хезмәте вәкилләре балаларны гаиләдән алганда кулланырга тиешле махсус инструкция эшләячәк, дип хәбәр итә «Татар-информ». Инструкция нигезендә, балаларны бары башка вариантлар, баланың әти-әнисенә ярдәм итәр мөмкинлек булмаган очракта гына алырга мөмкин булачак. Шул рәвешле балаларны идән пычрак яки суыткыч буш булу аркасында гаиләдән алулар тукталачак.

«НОРМАЛЬ ТОРМЫШ» өчен өч кешедән торган Россия гаиләсенең уртача айлык кереме 83 600 сум тәшкил итәргә тиеш. Шул ук вакытта шәһәр һәм авыл халкының хезмәт хакы күләме турындагы өметләре шактый аерыла. Әйтик, мегаполиста яшәүче өч кешелек гаиләгә «нормаль тормыш» өчен 118 мең сум таләп ителсә, авыл халкы 67 меңгә риза.

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

Бердәм дәүләт имтиханнарын бирдерүне гестапога әйләндерергә кирәкми.

(«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә әйткән сүзләре)

АБАУ

Яшел Үзәндә яшәүче 32 яшьлек ир-атка карата җинаять эше кузгатылган, дип хәбәр итә «Татар-информ». Ир-ат 2003 елда җирләнгән каенанасы каберен казырга теләгән. Каберне ул исерек килеш балалар көрәге белән казырга уйлый. Ир-ат җирләнгән каенанасының алтын эшләнмәләрен – бизәнү әйберләре һәм алтын коронкасын алырга ниятләгән. Әмма ул үзенең явыз ниятен ахырына җиткерә алмый. Аны күреп алалар һәм бу хакта полициягә мөрәҗәгать итәләр.

Курорт җыемын кертергә җыеналар

Хөкүмәт Дәүләт Думасына курорт җыемы турындагы канун проектын кертә. 2018 елдан, эксперимент рәвешендә, курорт инфраструктурасыннан файдаланган өчен җыем алырга ниятлиләр. Салымны Кырым, Алтай, Краснодар һәм Ставрополь өлкәләренә шифаханәләр һәм кунакханәләрдә ял итәргә баручылар түләячәк. Аннан аны Россиянең башка төбәкләренә дә кертү уйланыла. Курорт җыемы күләме төбәк хакимияте тарафыннан 100 сум күләме чамасында билгеләнеп, сезонга карап үзгәрергә дә мөмкин. Ул түләүченең объектта булу вакытына, курортның дәрәҗәсенә бәйле булачак. Канун проектыннан аңлашылганча, салым курорт инфраструктурасын үстерү өчен тотылачак.

Рамил Мифтахов, Татарстанның туристлык агентлыклары ассоциациясе президенты:

– Курорт салымын кертүне мин хуплыйм. Әгәр дә ул чынлап та курорт инфраструктурасын үстерүгә китсә, әлбәттә. 100 сум зур сумма түгел. Чит илләрдә дә бар мондый практика. Гарәп Әмирлекгендә бер көнгә салым – 4-5 доллар. Европа илләрендә – 5 евро. Аңа карап кына чит илгә йөрүне туктатмыйбыз. Без үзебездән салым алуларын хәтта белмәскә дә мөмкинбез. Курорт салымын бары тик кунакханә һәм шифаханәләрдә яшәүчеләр генә түләячәк. Йорт, бүлмә арендалап торучыларга бу кагылмый. Балалар, инвалидлар, ветераннарга түләү каралмаган. Борчылырлык урын юк.

ФОТОХӘБӘР

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанда «Шүлгәнташ» тыюлыгы янында музей төзеләчәк, дип яза «Кызыл таң» газетасы. Моның өчен 500-700 миллион сум акча таләп ителә. Шулай ук «ВДНХ-Экспо» территориясендә Хәзерге заман сәнгате музее оештыру планлаштырылган. 12 июньдә Россия тарихы музее ишекләрен ачачак.

Чуашиядә пациент белән табибны медиаторлар татулаштырачак. «Чуашиянең медицина ассоциациясе» иҗтимагый оешмасы каршында оештырылган Медиация үзәге ике арадагы бәхәсне судка кадәр хәл итәргә булышачак. Моның өчен махсус белгечләр әзерләнгән.

Мари Элда өйләнешүчеләр һәм бала табучыларның саны кимегән. Маристат быелның өч аена нәтиҗәләр чыгарган. Үлүчеләр саны туучыларга караганда 12,6 процентка арткан. 646 пар язылышкан, 631 пар аерылышкан. Узган ел белән чагыштырганда, өйләнешүчеләр 3,7 процентка кимегән. Ә аерылышучылар 10,9 процентка арткан, дип яза MariMedia.ru

МАГНИТ ДАВЫЛЛАРЫ

28-29 майда көчле магнит давыллары күзәтелергә мөмкин. Бу көнне йөрәк һәм нерв системасы авырулары булганнар гына түгел, балалар һәм өлкән яшьтәге кешеләр дә сәламәтлекләренә тагын да игътибарлырак булсыннар иде.

Сөт арта – бәя кими

АВЫЛ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Халык ничек кенә аһ-зар итсә дә, шәхси хуҗалыклардан сөт сатып алу бәяләре май башыннан шактый кимеде. Кыш айларында, сыерлар сөтне азрак биргән вакытта, уртача алганда, 20 сум түләнә иде, хәзерге вакытта әлеге бәя 17 сумнар тирәсендә тибрәлә. Шәхси хуҗалыкларда тир түгеп ризык табучыларның кәефләре тагын да ныграк төшәргә охшап тора, чөнки июнь башыннан сөт сатып алу бәяләре тагын арзанаерга мөмкин. Шәхси эшмәкәрләр үзләре моны илебезгә читтән, аерым алганда Белоруссиядән, коры сөтнең күп килүе, сөт ризыкларын сатуның кыенлашуы белән аңлаталар. Әлеге хәлгә карата май башында Татарстан премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов та үз фикерен белдергән иде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Сөт җыю, эшкәртү белән шөгыльләнүче бизнес субъектларына административ рәвештә йогынты ясап булыр идеме икән? Дөрес, авыл хуҗалыгы җирлекләре башлыклары белән дә бу юнәлештә эш башкарабыз, ләкин без теләгәнчә үк барып чыкмый. Кышкы чор бәясен саклап кала алсак, бик әйбәт булыр иде дә. Җәй бит сөт күбрәк җитештерелә торган чор. Кызганыч, кибеттә бәяләр төшми. Ә әзерләү предприятиеләре һәм арадашчылар, кибетләр арасында мөнәсәбәтләрне көйләп булмау аркасында, халыкның безгә ризасызлыгы, әлбәттә, бар инде. «Хөкүмәт кая карый?» – дияргә мөмкиннәр. Без үзебезчә анализлап барабыз, әзерләүчеләргә дә үзара кемдә нинди бәя булуы турында мәгълүматлар да җиткерәбез. Кемдәдер сөт бәясе 16-17 сумга төшкән булса, шул ук вакытта 19-20 сумны саклаучылар да бар. Мин үзем дә аларга еш кына мөрәҗәгать итәм. Район муниципаль җитәкчелеге бу мәсьәләне күбрәк игътибарда тота алыр иде, – дигән иде ул.

Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан 19 майга алынган мәгълүматлары буенча, халыктан җыелган сөт бәясе Питрәч районында 20 сум дип куелган. Ә менә Югары Ослан районында шәхси хуҗалыклардан сөт сатып алу бәясе нибары 15 сум гына. Шушы районның Татар Макылы авылында яшәүче фермер Роберт Сибгатов: «Казанга иң якын район булсак та, бездә иң арзан продукция», – дип белдерә.

– Минем хуҗалыкта 90 баш эре терлек бар. Савым сыерлары – 38 баш. Алар тәүлегенә уртача 550 литр сөт бирә. Сөтне моңа кадәр 15 сумнан җыялар иде. Халык арасында зур ыгы-зыгы булып алганнан соң, шушы көннәрдә генә 50 тиенгә арттырдылар. Тир түгеп алган продукцияне бигрәк арзанга бирәбез инде. Безнең районда, гомумән, сөт җыючылар юк. Кайбыч районыннан бер абзый җыя. Хуҗалыгымдагы сөтне үзем тапшырыр идем дә, техникам да бар югыйсә. Әмма хәтта май заводына турыдан-туры китергән очракта да алар, 17 сумнан артыгын бирә алмыйбыз, диләр. Ә ул бәядән тапшырсам, хезмәтем үз-үзен акламаячак, – ди Роберт әфәнде.

Ике яклы фикерне ишетергә теләп, Азнакай районының Беренче Май авылында сөт җыючы эшмәкәр Илмир Гәрәфиевкә дә чыктык.

– Апрельдә халыкка сөт өчен 16 сум 50 тиен бирдек. Бездән «Ислам» авыл хуҗалыгы предприятиесе 18 сум белән ала. Аңа кадәр 18 сум 50 тиенгә тапшырган идем. Кыш көне шәхси хуҗалыклардан җыелган сөткә 18-19 сум түләп, предприятиегә 21-21 сум 50 тиенгә тапшырдык. Май заводында 15 майда бирелгән белдерү кәгазендә сөтне 15 сум 50 тиеннән алырга дип язганнар иде. Шуннан соң халык тавыш күтәргәч, 50 тиенгә арттырганнар. Чыннан да, бәяләрне бик нык төшерәләр. Бу бездән генә тора торган эш түгел. Май заводлары, бүген сөт бөтенләй кирәк түгел, ди. Майлылыкның да формуласын бик «шома» итеп ясадылар бит хәзер. Аның белән исәпләгәндә, майлылыгы югары булган очракта да, бәя аз арта. Бүгенге көндә үземнең хуҗалыкта 13 савым сыеры бар. Сөткә бәя югары булганда, эшләве дә рәхәт. Сөт бәясе 1-2 сумга төшү үзен нык сиздерә, – ди ул.

Балтач районында, башкалар белән чагыштырганда, халыкка сөт өчен түләнә торган акча алай ук начар түгел. Хәзерге вакытта район буенча уртача бәя – 19 сум 44 тиен. Районның азык-төлек һәм авыл хуҗалыгы идарәсе консультанты Рафис Вәлиев:

– Районда сөт җыю ике юнәлештә оештырылган. Беренчесе – күмәк хуҗалыклар, икенчесе шәхси эшмәкәрләр аша. Бер үк җирлектә ике төрлесе дә эшли. Конкуренция булу авыл халкы өчен файдалы гына. Кем акчаны күбрәк түли, алар шуңа тапшыра. Моннан ике ел элек район башлыгы сөт җыючыларга конкрет бәя билгеләде: халыктан җыелган сөтнең бер килограммы өчен 1 сум 20 тиеннән дә артык акча алып калмаска. Шушы чиктә эшләүчеләр дә, кимрәк алучылар да бар. Ә сөткә бәяләргә килгәндә, ел башында аның базис бәясе (ягъни базис – 3,4 процент майлылыктагы сөтнең бер килограммы өчен) 23 сум булса, кызганычка, бүген 17 сум 50 тиенгә кадәр кимеде. Базис майлылыктан арткан һәр процент өчен өстәмә түләү каралган. Майлылык өчен фәкать күмәк хуҗалыклар аша эшләүче сөт җыючылар гына түли, шәхси эшмәкәрләрдә ул уртача бәядән чыгып исәпләнә. Сөт сатып алучы кампанияләр дә бер генә төрле бәядән сатып алмый. Менә шуларның барысыннан төрле бәя килеп чыга инде, – ди.

Апас районының Кече Болгаер авылында яшәүче газета укучыбыз Сәлимә Хәйруллина: «Әлегә бездә сөтне 17 сумнан җыялар. Халыктан җыя торган сөтнең бәясе җәйге чорда ай саен төшсә дә, шәһәр кибетләрендәге бәя бер тиенгә дә кимеми», – дип борчылуын белдерә. Тагын бер газета укучыбыз Фирая Ибраһимова әйтүенчә, Биектау районының Кече Битаман авылында яшәүчеләр дә сөтне 17 сумнан тапшыра. Ә менә Яшел Үзән районының Кече Ачасыр авылыннан өч гаилә узган елларда тапшырган сөт өчен дә акчаларын ала алмыйча азаплана икән.

– Үзебезнең районга караган «Нур» оешмасына сөт тапшырган идек. Әмма акчаларыбызны бүгенгә кадәр ала алганыбыз юк. Безнең гаиләгә генә 30 мең бурычы бар. Кая гына мөрәҗәгать итсәк тә, очына чыга алганыбыз юк. Хәзерге вакытта сөтне Ульяновскидан килеп җыялар. Бер литрга 16 сум түлиләр. Шөкер, монысы акчаларны ике атна саен биреп бара, – ди Розалия Хәялиева.

СӨТ ҺӘМ СӨТ РИЗЫКЛАРЫНЫҢ КАЙБЕР РАЙОННАРДАГЫ УРТАЧА БӘЯЛӘРЕ

Шәһәр һәм районнар	2,5% майлылыктагы сөт (литр)	1 % майлылыктагы кефир (литр)	2,5 % майлылыктагы катык (литр)	1 % майлылыктагы каймак (литр)	Майсыз эремчек (кг)	Каплы ак май (кг)
Әгерҗе районы	50,00	47,50	59,50	142,80	240,00	520,00
Азнакай районы	37,90	40,00	55,90	131,33	198,20	522,89
Аксубай районы	44,20	44,00	52,33	136,50	235,60	497,03
Актаныш районы	53,81	47,63	55,50	138,93	242,15	523,75
Алексеевск районы	44,33	46,00	55,60	126,00	206,00	472,22
Әлки районы	37,17	44,93	53,20	133,33	188,00	472,22
Арча районы	42,20	48,80	60,55	143,08	244,47	474,47
Әтнә районы	45,00	46,79	64,20	160,46	204,00	515,28
Балтач районы	40,40	46,80	60,40	143,40	236,40	495,40
Буа районы	44,67	48,09	64,95	139,47	241,39	532,57
Биектау районы	44,34	49,89	63,72	146,03	253,15	515,34
Алабуга районы	42,40	46,08	51,56	139,00	212,04	492,62
Зәй һәм Зәй районы	40,21	43,35	44,60	141,88	206,56	489,89
Яшел Үзән районы	40,65	46,24	63,00	133,31	275,50	508,76
Казан	43,68	49,01	61,42	140,21	246,25	506,44
Кама Тамагы районы	42,25	49,00	62,10	133,54	212,07	482,20
Кукмара районы	43,86	50,33	66,60	151,96	221,00	465,47
Лаеш районы	44,07	55,25	61,90	147,07	254,70	514,94
Лениногорск районы	35,78	43,40	53,56	132,40	223,57	362,30
Мөслим районы	36,89	44,51	57,58	146,49	208,28	478,33
Чаллы	46,36	45,47	60,06	139,28	236,25	511,38
Түбән Кама районы	42,88	44,45	59,92	140,24	225,16	496,11
Яңа Чишмә районы	39,98	44,00	53,20	126,00	208,00	472,22
Питрәч районы	46,24	50,00	64,36	144,20	265,29	540,14
Балык Бистәсе	44,63	54,20	65,67	140,82	209,58	547,09
Саба районы	54,02	56,00	63,58	148,49	250,67	483,67
Тәтеш районы	40,70	45,70	56,87	125,14	211,83	456,45
Теләче районы	54,17	60,40	57,90	144,11	224,00	457,34
Чирмешән районы	43,59	42,64	49,06	140,92	226,60	471,61
Татарстан буенча уртача бәя	**43,52**	**47,63**	**58,69**	**140,37**	**226,75**	**491,49**

Мәгълүматлар республиканың Дәүләт алкоголь инспекциясе сайтыннан алынды (2017 елның 19 маена)

Айсылу Лерон:
«Инвалид булып тума яки ничек энекәшемне югалтмый калдым»

Татарстанда **316 049** инвалид яши. Бу барлык халыкның **8,1** процентын тәшкил итә. Аларның **15 023**е – инвалид балалар.

Шагыйрь Ләбиб Лерон белән хатыны Фидания апа тумыштан инвалид уллары Бәхтияр турында бик яратып сөйлиләр. «Кызлар да энекәшләре өчен үлеп тора, телләрендә «Безнең Бәхтияр, безнең Бәхтияр» генә», – дигәннәре истә. Күптән түгел Бәхтиярне, кеше куркыта дип, «Парк Хаус» сәүдә үзәгеннән куып чыгарганнар. Бу хакта апасы – алып баручы, блоггер Айсылу Лерон инстаграм битендә хәбәр итте. «Инвалид булып тума яки мин ничек энекәшемне югалтмый калдым», – дип башлаган ул. Айсылуның үзе белән элемтәгә чыктык.

– Бәхтияр – тумыштан инвалид. Сөйләшми, авырлык белән хәрәкәтләнә. Яше 26да, ике метрлы буйлы булса да, акылы бер яшьлек сабыйныкы сыман. Әмма без аны ничек бар, шулай яратабыз. Ул да безне бик ярата, безне генә түгел, бөтен дөньяны кочарга әзер сыман. Аңа кибетләрдә йөрү аеруча ошый. Бу аның өчен бәйрәм кебек. Моңа кадәр дә аның белән сәүдә үзәкләрендә булганыбыз бар иде. Карап торышка сәер хәрәкәтләнүен, үзен гадәти булмаганча тотуын күреп, беркемнең дә кисәтү ясаганы булмады. Бу юлы «Парк Хаус» сәүдә үзәгендә булган хәл безне шок хәлендә калдырды, – дип сөйләде Айсылу.

Ул кечкенә кызы, энекәше белән сәүдә үзәгендә бер кибеткә туктаган арада, Бәхтияр юк була.

– Башта килер дип көттем. Аннары борчыла башладым. Кешеләрдән сораша торгач, Бәхтиярне сакчылар алып киткәнен аңладым. Алар миңа энекәшемне урамга чыгарып куйганнарын әйттеләр. Имеш, ул, үз-үзен тотышы, башкалар төсле хәрәкәтләнмәве белән, башкаларны куркыткан, – ди Айсылу. – Берәр исерек булса, башкаларга сукса, кычкырса, сакчының гамәлләрен аңлар идем. Бәхтияр бит беркемгә зыян салмаган. Энекәшемнең киемнәре яхшы, ул чиста-пөхтә йөри. Сакчылар, «авыру малай югалган», дип игълан да бирә алалар иде. Аны урамга чыгарып җибәрү – мәгънәсезлек, минемчә. Ул бит берни аңлата алмый. Югалса, машина астына керсә?

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәр итүенчә, гомумән алганда, республикада инвалидларның тормышын яхшыртуга зур игътибар бирелә. Аларның җәмгыятьтә социальләшүен җиңеләйтү максатында күп эш башкарыла. 2016 елдан гамәлгә кергән закон нигезендә, инвалидларны социаль яктан яклау көчәйтелгән. Әлеге законда физик яктан мөмкинлеге чикле кешегә инвалидлыгы аркасында ниндидер хезмәт күрсәтергә теләмиләр яки объектка кертмиләр икән, бу дискриминация булып санала. Тик рухи битарафлык – җәмгыятьнең иң катлаулы авыруы шул.

Мондый очракта нишләргә?

Татарстанның кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле **Сәрия Сабурская**:

– Сәүдә үзәге сакчыларының гамәлләре ачуны чыгара. Кеше кайда булырга тели, шунда бара. Бу хокукны беркемнең дә чикләргә хакы юк. Әйе, без төрле! Тән төсе, дин, үз-үзебезне тотышыбыз, тышкы кыяфәт белән аерылабыз. Әмма бу сакчыларның гамәлләрен акламый. Бәхтияр башкалар шикелле түгел, аңа игътибар, аңлау күбрәк таләп ителә. Кызганыч, мондый хәлләр булып тора, әйтик, инвалидны самолетка кертмәгәннәр, кафеда хезмәт күрсәтмәгәннәр. Матбугатка килеп ирешкән бу вакыйгалар җәмгыятьтә шау-шу уятмый калмый. Мондый очракта Бәхтиярнең туганнары, кешенең конституция хокуклары чикләнү сәбәпле, прокуратурага, шулай ук сәүдә үзәге хезмәткәрләре түбәнсетүне әйтеп, судка мөрәҗәгать итә ала. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, гаепләр административ (РФ КоАП 5.61 маддә), җинаять җаваплылыгына да (РФ ЖК, 282 маддә) тартылырга мөмкин. Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиллеккә язмача гариза тапшырырга да була. Татарстанның инвалидлар җәмгыяте, республикада эшли торган юридик клиникалар гаризаны бушлай тутырырга ярдәм итә алалар. Инвалидларга карата хөрмәт, аңлау, түземлелек булмаган җәмгыятьне цивилизацияле дип әйтеп булмый. Безгә «үзенчәлекле» кешеләргә карата мөнәсәбәтне үзгәртергә һәм аларга җәмгыятькә яраклашырга ярдәм итәргә кирәк.

Шәһри Казан тыңлый

Сорау, тәкъдим, фикерләрегезне редакциябезгә **8 (843) 562-50-12, 562-50-03** номерлары аша юллый аласыз.

«Күрше бүлмәдә эт яши»

«Түзәр хәлем калмады... Шундый тормышта яшәр өчен гомер буе бил бөктемме?» – дип зарланып шалтыратты Әмәт бистәсеннән Асия Гобәйдуллина.

Эльвира МОЗАФФАР,
Казан, Әмәт бистәсе

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Асия апа яшәгән ике катлы кирпеч йорт 1958 елда ук салынган. Беренче каттагылар, фатирларын зурайтып, ишегалдына янкорма төзеп куйганнар. Без сораштырган кешеләр арасында йорт начар дип зарланучылар булмады да диярлек. Баксаң, Бөек Ватан сугышы ветераны 92 яшьлек Асия апага башка нәрсәләр тынгылык бирми икән. Ул өске каттагы күршесе белән тыныша алмый. Күршесе су бастырганнан соң, Асия апаның түшәме ярылган. Күршесенә бернича тапкыр ремонт турында сүз кузгатып караган, әмма тегесе кул гына селти, ди.

– Су басуы бер хәл, эте яман аның, өргән тавышка йоклый алмый ятам. Ник мин шушы яшемә җитеп, шулай газапланырга тиеш соң? Яшьлегемдә дә җитәрлек михнәт күрдем югыйсә, – дип зар елый Асия апа.

Укучыбыз тумышы белән Спас районының Әҗмәр авылыннан. Сугыш елларында мәктәптә укыткан. Яу кырыннан яраланып кайткан әтиләре гүр иясе булганнан соң, карап торган сыерлары да үлеп киткәч, хәерчелектә калган гаилә яшь кызны Казанга озата. Ул башта Казан университетына китапханәче белгечлегенә укырга керә. Әмма бер атна укыгач, кияргә кием, ашарга ризык булмаудан, барысын да ташлап, итек басу фабрикасына эшкә урнаша. Озак еллар төрле завод-фабрикаларда эшли. Әмәт бистәсендәге фатиры да үз тырышлыгы нәтиҗәсендә алынган.

– Бу йортны үзебез салып чыктык дисәң дә була. Төзелеш вакытында да күп көч куелды. Эчке эшләрне башкарганда да үзебез башлап йөрдек. Миңа ремонт ясарга ярдәм иткән күршедәге ир-атка бүген дә бурычымны түлим әле. Шуңа да кадерле бу йорт безгә, үзем теләгәнчә яшәргә мөмкинлекләр булмавы гына аяныч, – ди Асия апа.

Янында ярдәм итәр кешесе дә юк. Ире күптән вафат. Бертуганнары да еракта. Кызы Мәскәү каласында яши. Улы фаҗигале төстә үлгән. Мәскәүдә яшәүче оныгы бернича мәртәбә үзе белән алып китәргә теләгән анысы, тик үзе дә вакытлыча фатирда яшәгәнгә, өстәвенә физик яктан мөмкинлеге чикле баласын да тәрбияләгәнгә, тагын тукталып калган.

– Ярый, социаль яклау бүлегеннән хезмәткәрләр килеп ярдәм итә. Чүбемне түгәләр, памперслар, кирәкле даруларны алып кайтып бирәләр, – ди Асия апа.

Ә менә башка эшләрендә аңа каршы йортта яшәүче бер кыз булыша. Дөрес, бушка түгел, хезмәте өчен Асия апа аңа ай саен 10 мең сум түләп тора.

Өске каттагы күршесе белән сөйләшергә теләп ишеген шакысак та, ачучы булмады. Су басу мәсьәләсендә барысы да аңлашыла кебек. Закон нигезендә, бу очракта барысын да суд аша хәл итәргә була. Әгәр бу хәл килеп чыгуда идарәче компаниянең катнашы юк икән (авария, стояк шартлау һәм башка очраклар), су басу өчен йорт милекчеләре җавап тота. Күршеләр китергән зыянны капларга тиеш була. Суд карары нигезендә, моны мәҗбүри эшләтергә дә мөмкин. Ә менә фатирда эт өрүгә килгәндә, Россия законнар җыелмасында моңа кагылышлысы очрамый. Дөрес, ни гаҗәп тоелса да, кайбер төбәкләрдә фатирда эт өрүгә карата да аерым кагыйдәләр кабул ителгән икән. Мурманда, мәсәлән, «Административ тәртип бозулар турында»гы закон нигезендә, төнлә эт өрсә, 3-5 мең сум штраф каралган, ди.

– Фатир кешенең шәхси милке икән, без хуҗаны эт асраганы өчен җаваплылыкка тарта алмыйбыз, әлбәттә. «Тынычлык турында»гы закон буенча, 23.00 сәгатьтән 7.00гә кадәр тынычлык булырга тиеш. Әгәр эт төнлә йокларга комачаулый икән, күршеләре бу хакта участок полициясенә мөрәҗәгать итә ала. Шикаять нигезендә, без эт хуҗасы белән сөйләшәбез, әлеге мәсьәләне хәл итәргә тырышачакбыз, – диде «Вишневский» полиция бүлегендә участок полициясе Руслан Әбебәкеров.

ЗУРЛАРЧА УЙНАУ

Психолог Люция Закирҗанова:

«Гаджетлар уенчыкларны гына түгел, әниләрне дә алыштыра»

Кесә телефонының балалар өчен тискәре һәм уңай яклары

Ничек диләр әле? Хәзерге замана балалары туганда ук акыллы булып туа, диләрме? Чынлап та, тәпи дә китмәгән сабыйның телефонны белеп баскалап утыруын күреп гаҗәпләнәсең. Гаджетларны ул уенчык дип кабул итми, аны авызына да капмый, олылар кебек, төймәләренә баса, сенсор экраннан да файдалана белә. Азрак үскәч, беркем өйрәтмичә дә телефоннан шалтырата, сөйләшә ала. Кайбер балалар гаджеттагы кушымталар аша санарга, укырга, инглиз теленә өйрәнә. Балага кечкенә чактан ук телефон тоттыру кирәкме? Гаджетларның кечкенә балаларга файдасы һәм тискәре тәэсире турында психолог Люция Закирҗанова белән сөйләштек.

Эльвира МОЗАФФАР

actudappoint.com

МӘЧЕНЕҢ ДӘ АЙПАДЫ БАР

– Гел алышынып торган төсләр, күңелле музыка булганга, аралашу мөмкинлегә биргәнгә, телефоннар кечкенә сабыйларда кызыксыну уята. Җитмәсә анда видео, мультфильмнар да карарга мөмкин. Шуңа да гаджетлар еш кына уенчыкны гына түгел, әниләрне дә алыштыра, – дип саный Люция.

Сораштырулар күрсәткәнчә, баксаң, әти-әниләр үзләре үк балага, комачауламасын өчен, телефон бирә. Бер уйласаң, чынлап та җайлы бит. Көйсез баланы юатыр өчен телефон тоттырасың да эш тәмам. Ни хикмәт, телефон баланы әнисенә караганда тизрәк тынычландыра. Еш кына сырхауханәләрдә чират көткәндә, мөһим эш белән мәшгуль булганда, әти-әниләр шулай эшли. Күпләр өчен айпадлар, планшетлар ярдәмче: «уенчыкларыңны җыйсаң, телефон бирәм», «ашамасаң, планшетта утырмаячаксың», «яхшы укысаң, телефон алабыз» дигәнне ата-аналардан еш ишетергә туры килә. Психологлар үткәргән тәҗрибәләр буенча, 1994 елларда балалар рәсемдә гаилә белән табигатьтә һава сулап йөргәнен сурәтләсә, хәзер хәтта мәчене дә айпад белән ясыйлар икән.

– Ияләшү өчен, балага планшет дөньясында бер тапкыр булып карау җитә. Өлкәннәр үзләрен контрольдә тота алса, телефонны яңалыклар белән танышу, социаль челтәрләрдәге хәбәрләрне күзәтү, аралашу өчен файдаланса, балалар чикне белми, туктап кала алмый, – ди психолог. – Балаларның тәпи киткәнче үк гаджетлардан куллана белүе дә гаҗәп түгел: беренчедән, алар губка кебек, барысын да үзенә сеңдереп бара, өлкәннәрне кабатлау хас, шуңа да әти-әнисенең гаджетларны ничек кулланганын күреп, ул моны җиңел эшли. Икенчедән, нәрсә дисәк тә, цивилизация бер урында тормый. Безнең балалар да заман белән бергә атлый. Бүгенгеләр совет заманы сабыйларыннан аерыла. Аларның психологияләре, танып белү сәләтләре дә үзгә.

ПСИХОЛОГЛАРДАН КИҢӘШЛӘР

ИСТӘ ТОТ!

✓ Өч яшькәчә сабыйларга елаганда юатыр өчен, комачауламасын дип телефон бирү дөрес түгел.
✓ Сабый телефон аша мультфильмнарны 20 минуттан артык карамаса хәерле.
✓ Чик-чамасын белгәндә компьютер уеннары, төренә карап, файдалы да булырга мөмкин. Алар тизлек реакциясен арттыра, тәвәккәллеккә, игътибарлы булырга өйрәтә.
✓ Башлангыч сыйныф укучысына кыйммәтле телефон алмагыз.
✓ Мәктәп укучысының, үзенә сиздерми генә, нинди сайтларга кергәнен, интернетта нинди мәгълүмат караганын күзәтеп барыгыз. Борчылырлык нәрсә тапсагыз, баланы әрләмәгез, тыныч кына аңлатыгыз. Бала сездән телефонын яшерә башламасын. Аның шикле сайтларга үзе эзләп түгел, төймә ялгыш басылып кергән булуын да истән чыгармагыз.
✓ Телефонга бәйлелек тумасын өчен, вакыт-вакыт гаджетларны читкә алып куярга өйрәнегез.

ТЕЛЕФОН ТИЗЛЕК РЕАКЦИЯСЕН АРТТЫРА

Психолог Люция Закирҗанова балага кечкенәдән телефон бирүгә катгый каршы.

– Башлангыч сыйныфларда, балалар бакчасында телефон бөтенләй кирәк түгел дип саныйм. Күп ата-аналар баланың куркынычсызлыгы өчен телефон ала. Бу – ялгыш фикер. Баланың куркынычсызлыгын тәрбиячеләр, укытучылар кайгырта. Аларда әти-әниләрнең эш телефоннарына кадәр бар. Берәр хәл була калса, һәрчак хәбәр итәчәкләр. Мәктәптән, балалар бакчасыннан һәркем үз сабыен каршы ала. Әмма усал ниятле кешеләр корбаны булыр өчен күп кирәкми. Балалар тиз ышанучан. Интернет дөньясында ниләр генә юк бит. Шулай ук мәктәптә укучылар арасында көнләшү хисе уяныргa, кемнең телефоны яхшырак дип, бер-берсен уздыру да булырга мөмкин. Балалар тәнәфестә, һәр буш минутларында да телефонга урелә. Бу үз чиратында укуга, уйлау сәләтенә тәэсир итә. Финанс ягыннан караганда да, кыйммәтле телефон төшеп ватылырга мөмкин. Болардан чыгып, балага телефон нигә кирәк, дим. Бала башкалар белән аралашканда, коммуникатив уеннарда ачыла, камилләшә. Ә гаджетлар тере аралашуны алыштыра, бу сабыйлар өчен файдага түгел, – ди Люция Закирҗанова.

Медицина фәннәре докторы, психотерапевт Римма Нәбиуллина, гаджетлар балада агрессия уята, дигән фикердә. Психиатрлар, гомумән, телефоннарга бәйлелекне психик авыруның яңа формасы дип ышандыра. Медицина ягыннан караганда да табиблар телефонның сәламәтлеккә тискәре тәэсире турында еш сөйли. Кесә телефоннарыннан еш файдаланучылар баш авырту, йокы килүдән зарлана. Алар ярсучан була, иммунитет кими, күз күрүе начарлана.

Ә менә балалар психологы Марина Романенко, чамасын белсәң, телефонның зыяны юк, дип саный. Киресенчә, интернеттагы уеннар тизлек реакциясен арттырырга өйрәтә, хәзерге заманда балаларның моңа кечкенәдән күнегүләре кирәк. Гаджетлар әти-әнине генә алыштырмасын иде һәм кечкенә сабыйлар телефонны көненә 20 минуттан да артык кулланмасын, дип киңәш итә ул.

Ә сез балагызга телефон бирәсезме?

Илмира Нәгыймова,
җырчы:

– Иң бәләкәенә – тугыз айлык балабызга телефон бирмим. Дөрес, ара-тирә телевизордан кечкенәләр өчен мультфильмнар күрсәтеп алабыз. Ә өч яшь ярымлык улыбызга көненә 15-20 минутка телефонда утырырга рөхсәт итәм. Сырхауханәдә йөгереп йөрмәсен өчен дә шәп ярдәмче ул телефон. Улым күбрәк телефон аша уйлау сәләтен үстерә торган, танып белүгә корылган күнекмәләр карый. Шулай итеп инглиз хәрефләрен, чит телдә 30га кадәр санарга өйрәнде. Русча 100гә кадәр саный белә. Әбисенә дә үзе шалтыратып ала. Телефонның зыяны барлыгын да беләм, тик шулай да чамасын белеп куллану ярыйдыр дип уйлыйм. Өстәвенә, үземнең вакытым җитеп бетмәгәндә, телефондагы кушымталар баланы күп кенә файдалы нәрсәләргә өйрәтергә мөмкин.

Галия Кәримова,
укучыбыз:

– Бала еламасын дип кулына телефон тоттырып, ничәсе ватылды инде. Трамвайда барганда көйсезләнә башласа, гел кесә телефоны ярдәмгә килә. Коляскада утырган яшь ярымлык улымны башкача тынычландыра алмыйм. Сәламәтлек өчен зарары бардыр инде, хәзерге заманда зыянсыз нәрсә бармыни ул? Гел тыңлый-тыңлый, балам кайбер шигырьләрне яттан өйрәнде, җырлар кабатлый. Телефон няня кебек.

Булмый инде булмагач...

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

Бәхетеңне мүкләк сыер сөзсә, көтү көткән акчаңны да ала алмассың, диләрме әле ул? Юк, алай язмышыма үлә-бетеп зарланасым килми, кем әйткәндәй, булганына шөкер, тик шулай да әгәр чит илгә бару турында сүз чыкса, мин алдан ук белеп торам – барып чыкмаячак бу эш. Чөнки әлеге мәсьәләдә шактый гына ачы тәҗрибәм җыелды.

Равил Сабыр 2009 елда беренче тапкыр Төркиягә баргач.

«Равил чит илдән кайтып та кермәс инде!» – дигәннәр иде безнең класс кызлары мәктәпне тәмамлаганда. Алар минем Казан университетының журфагына укырга керергә җыенганымны беләләр иде һәм, күрәсең, журналистларны бертуктаусыз чит илгә командировкага йөрүче кешеләр дип күзалдына китергәннәрдер инде. Һәм чыннан да беренче мөмкинлек университетта укуның икенче аенда ук килеп туды. Дөрес, ул потенциаль сәяхәт журналист эше белән дә, хәтта журфакта уку белән дә берничек тә бәйле түгел иде. Хәзер аңлатыбрак язам...

I курста өч-дүрт көн укыдык микән, юк микән, бәрәңгегә җыярга җибәрделәр безне. Арча районының Сөрде дигән авылы иде ул, анда юл дигән нәрсәнең «ю» хәрефе дә юк иде. Аңлатып үтим, 1990 елда булган хәлләрне искә төшереп язуым бит. Тик хәзер дә әллә ни зур үзгәреш күзәтелми икән, чөнки Ютубка шушы авыл кешеләре төшергән 12 минутлык мәзәк мини-фильм (https://www.youtube.com/watch?v=km2DYK3r4bQ) урнаштырганнар. Аптырагач, җитәкчеләрнең бу проблемага игътибарын авыл халкы шул рәвешле җәлеп итәргә булган.

28 көн эшләдек без ул Сөрдедә, шул арада берәр көн яңгыр яумый калды микән? 28 көн буена, муеннан сазга бата-чума, бәрәңге чүпләдек. Кич белән басудан кайтып керәбез дә, башта мунчага барып, киемнәребезне юып киптерергә эләбез, аннары үзебез юынабыз. Ашарга көн саен үзебез басудан алып кайткан бәрәңге, шуны ашказанына «ыргытабыз» да, матур киемнәр киеп, чыгып чабабыз клубка, кызлар янына. Кайсы көнне бердә кайтасың, кайсы көнне өчтә. Ә иртән тору көн саен сәгать алтыда, будильник урынына радиодан СССР гимны яңгырый.

Өстәвенә колхоз рәисе бик явыз бер абый иде, мактаганын хәтерләмим, эшләмисез дип сүгәргә ярата иде. Без – I һәм II курс студентлары – барыбыз да диярлек авыл балалары, ул сүккән саен, һаман да ныграк тырышып эшли идек. Киткәндә: «Сезнең кебек җир җимертеп эшләгән студентларны күргән юк иде әле», – диделәр.

Бүгенгедәй хәтерлим, көндезге өчләр тирәсендә Казанга кайтып җиттек. Мин чыбык очы хәтле генә туган бер әбекәйнең фатирында бүлмә алып тора идем. Кайтып кердем дә, идәнгә матрас җәеп, йокларга яттым. Шулкадәр нык арылган иде, чишенергә дә хәл калмады. Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз – юк, тик икенче көнне сәгать берләр тирәсендә генә уяндым мин. 22 сәгать йоклаганмын! Селкенеп тә карамаганмын хәтта – нинди позада йоклап китсәм, шулай уяндым. Чын-чынлап аруың җитсә, алай да була икән...

Берничә көннән Казан университетыннан колхоз рәисеннән рәхмәт хаты килеп төшкән. Шуны укыгач, студентлар профкомы безне фидакарь хезмәтебез өчен бүләкләргә уйлаган. «Бушка экскурсиягә җибәрәбез Таллинга, җыеныгыз», – диделәр безгә. И шатланганнарыбыз!

Әйткәнемчә, 1990 ел бу, СССР таркалып бетмәсә дә, Балтыйк буе республикалары бәйсезлек игълан иткән иде инде, шуңа күрә Эстония – безнең өчен чып-чын чит ил иде.

Билгеләнгән көнне әйтелгән вакытка, дулкынлана-дулкынлана чемоданнарны өстерәп, университетның төп бинасы каршындагы Ленин һәйкәле янына (сковородкага) җыелдык, ләкин шуннан ерак китеп булмады. «Кире кайтырга Таллин аэропортында очкычка салырга ягулык юк, шуңа күрә бу юлы бара алмыйбыз. Тик сез бер дә борчылмагыз, киләсе атнада без сезне Вильнюска алып барабыз», – диделәр. Кәефләр кырылды инде, әлбәттә, Литвада да ягулык булмаса, дип мыгырданышып алдык, әмма күңелдә өмет бар иде әле. Ул өметкә акланырга гына язмады, бер атна узгач, Ригага барырга теләүчеләр исемлеген төзи башладылар. Мин язылып та тормадым, булмый инде ул бер булмагач...

Бу хәлләрдән соң шактый гомер узды. Хәтерем ялгышмаса, 2011 елда бугай, бер федераль компания бушка Сербиягә барып кайтырга тәкъдим итте. Мәшһүр режиссер Эмир Кустурица төзегән Мечавник дигән этнографик авылга барасың, шунда өчме-дүртме көн ял итәсең, теге компания чыгарган яңа автомобильгә тест-драйв уздырасың да кайткач шул турыда газетага мәкалә язасың.

Документларның күчермәләрен соратып алдылар – паспорт, ИНН, страховка, тегесен-монысын. Берзаман чираттагы мәртәбә шылтыратып сорыйлар бу компания хезмәткәрләре: «Сезнең чит илгә чыгу паспорты нинди датага кадәр бирелгән?» Ачып карасам, паспортның гамәлдә булу вакыты без Сербиядән кайткач өч көннән бетә. Ә бу илдәге кагыйдәләр буенча ул өч көн генә җитми, кимендә өч ай булырга тиеш икән. Шундый алып барасылары килгән иде инде мине Мечавникка теге компания хезмәткәрләренең! Шылтыратмаган урыннары, сөйләшмәгән кешеләре калмады, тик юк, булмый инде булмагач! Минем урынга Сербиягә башка журналист очты...

Шул ук елны бугай, Чаллы татар драма театры Төркиянең Конья шәһәрендә узачак «Мең сулыш һәм бер тавыш» халыкара театраль фестиваленә чакыру алган иде. Сайлап алу комиссиясе минем пьеса буенча куелган «Хәят» спектаклендә тукталган. Театрның директоры Рашат әфәнде Фәйзерахманов: «Делегациягә сине дә әбәзәтелни кертәбез», – диде һәм газетада хәбәр бирүемне сорады.

– Рашат Фәесханович, безнең якта: «Булмаган бия, тумаган колын, атланма, улым, билен сындырырсың», – дигән сүз бар. Әллә газетага бирергә ашыкмыйкмы? Бер ай бар бит әле фестиваль башланганчы, ниләр генә булмас дөньяда? – дидем мин, үземнең ачы тәҗрибәмне истә тотып.

– Ни сөйлисең син, Равил?! Әллә ничә татар, башкорт театры барып кайтты бит инде ул фестивальгә! Нишләп безгә килеп терәлгәч кенә нидер булырга тиеш әле ул?! Ю-у-у-к, әбәзәтелни барабыз! – дип кырт кисте Рашат әфәнде.

Гөнаһ шомлыгы, нәкъ шул вакытта фестивальне оештыручы ТЮРКСОЙ оешмасында ниндидер проблемалар килеп чыкты, акчалары җитми идеме соң инде шунда, кыскасы, тагын бушлай чит илгә барып кайту тәтемәде миңа.

Рашат әфәнденең тагын бер фестивальгә алып барасы килгән иде мине. Анысы 2014 елда, Төрекмәнстанга, Ашхабад шәһәренә, «Бәхетле чорның театраль сәнгате» дип исемләнгән II халыкара фестивальгә. Мин редакторымнан командировка сорап карадым – риза булмады. Аннары үз хисабыма ял сорадым – бирмәде.

– Фестивальдән репортаж, бүгенге Төрекмәнстан турында очерк, бер-ике кызыклы әңгәмәдәш белән интервьюлар яздырып алып кайтырмын. Барып кайтыйм инде, кызык ич! – дим.

– Мин Төрекмәнстанда ике ел хезмәт иттем. Анда эссе һәм еланнар бик күп. Бер кызык та юк анда, – дип кырт кисте нәчәлствы.

Дәүләт хисабына чит илгә минем урынга тагын башка кеше китте.

Тагын берсендә Алматыда бөгелмәләләр уздырган Сабан туена барырга чакырганнар иде. Нигә бара алмый калганымны җан үртәп язып торасым да килми. Әйтәм бит, булмый инде булмагач...

Теге сәвит вакытында булган бит әле «неблагонадежный», «невыездной» дигән кешеләр, андыйларны чит илгә чыгармаганнар? Менә мин дә шундыйрак кеше булып чыгам инде. Ярамый миңа чит илгә барырга. Бушка ярамый. Ә үз акчаңа булса – пажалысты!

Барып кайттым мин алай да Төркиягә! Анысы да артык акча булудан түгел, киресенчә, акча юклыктан килеп чыкты. 2008 ел финанс кризисы китереп бәргәч, ул чакта эшләгән редакциядә башта бер атнага хезмәт хакын тоткарлый башладылар, аннары – ике атнага, бер айга, ике, өч... Аптырагач, кердем нәчәлствы янына. «Болай булмый, – мин әйтәм, – әйдәгез, берәр нәрсә уйлыйк, хәл итик». Иттек. Ике бәясенә диярлек Төркиянең Аланья шәһәренә ике кешегә бер атналык юллама бирделәр хезмәт хакы исәбенә. Шулай итеп хатыным белән Төркияне күреп, Урта диңгездә коенып кайттык.

Менә шулай: кемнеңдер бәхете – ялдан, кемнекедер – эштән. Кайсы бәхетләрәк сезнеңчә?

СОРАУ-ҖАВАП

Ирем вафат булды. Ялгызым гына калдым. Пенсиям кечкенә. Мин иремнең пенсиясен үземә рәсмиләштерә аламмы? Моның өчен нишләргә?

Мөслимә Шәрифуллина,
Казан.

Сорауга Татарстан Пенсия фондының Вахитов районы бүлекчәсендә әйдәп баручы эксперт белгеч **Галина Абдрашитова** җавап бирә.

– Әгәр ирегез гаиләдә бердәнбер керем китерүче булган икән, аның вафатыннан соң, тәрбиячене югалту буенча пенсия рәсмиләштерергә мөмкин. Бу очракта ир-атның тол калган хатыны үз пенсиясен алмаячак. Бер кеше ике төр пенсия ала алмый (искәрмә очракларда гына бу рөхсәт ителә). Ирнең пенсиясенә күчкәндә, дөресрәк әйтсәк, тәрбиячене югалту буенча пенсия алганда ныклап уйларга кирәк. Үз пенсияң белән чагыштырып, ике төр пенсияне дә кабат санатып, үзегезгә отышлысын сайларга киңәш итәм. Аннары теркәлү урыны буенча пенсия бүлегенә барып, гариза язарга кирәк булачак.

Әтиебез Бөек Ватан сугышы ветераны, III группа инвалид иде. 1977 елны 54 яшендә вафат булды. Аңа инвалидлык буенча 56 сум пенсия билгеләнгән булган. Хөкүмәт тарафыннан бирелгән медальләре дә бар. Бөтен документлары саклана. Әтиебез 30 ел буе бу пенсиясен бер тапкыр да алмаган. Әтиебезгә тиеш булган бу акчаларны безгә ничек алырга мөмкин? Моның өчен кая мөрәҗәгать итәргә?

Закировлар,
Апас.

– Кызганыч, әмма закон нигезендә, әтиегезнең пенсиясе сезгә мирас булып күчә алмый. Шуңа да аның вафатыннан соң ул акчаларны ала алмыйсыз. Тулырак мәгълүматны теркәлү урыны буенча пенсия бүлегендә ачыклый аласыз.

«ШӘҺРИ КАЗАН»нан – алма бакчасы

«Шәһри Казан» газетасы һәм Югары Ослан районының Ямбулат авылындагы «Заря» питомнигыннан бүләккә алмагач үсентеләре алуның әллә ни кыенлыгы юк. Газетадагы анкетаны тутырып, 2017 елның II яртыеллыгына язылу турындагы квитанцияне редакциягә җибәрергә һәм җирәбә нәтиҗәләрен генә көтәргә кирәк. Үзегезгә ничек җайлы, шулай эшләгез, без аларны почта аша да, электрон адресыбызга да, «ватсап» аша да, социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә дә кабул итәбез. Бүләк ике атна саен уйнатыла. Җирәбә уйнатуны видеога төшереп, **www.shahrikazan.com** сайтында урнаштырабыз.

Әйдәгез, алма бакчасында «Шәһри Казан» укыйк әле!

Чираттагы җирәбә 31 майда уйнатыла.

ИНДЕКСЛАР

П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **450 сум.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **930 сум.**

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон________________

____

2. Яшегез________________

3. Шөгылегез________________

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?________________

____

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?________________

____

____

6. Газетага ничек язылсасыз:

почта бүлекчәсендә _____

хат ташучы өйгә килә _____

интернет аша _____

____

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?

____

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә?

____

____

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?________________

____

____

____

____

10. Газетаның миңа иң ошаган:________________

____

____

ошамаган яклары:________________

____

____

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?

____

____

____

____

Языл → **Анкетаны тутыр** → **Җибәр**

«Шәһри Казан» газетасына почта бүлекчәләрендә яки интернет аша языл

Анкета, квитанцияләр, «Алмагач» дигән тамга белән, түбәндәге адресларга кабул ителә:

Почта аша: 420066, Казан, Чистай урамы, 5нче йорт, «Шәһри Казан» редакциясе

Электрон почта: shahri-kazan@tatmedia.com

Ватсап: 8 917-851-69-62

Социаль челтәрләрдәге төркемнәр: vk.com/shahrikazanda facebook.com/shahrikazan ok.ru/shrikazan

Газетага ничек язылырга?

1. ТАТАРСТАННЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ПОЧТА БҮЛЕГЕНДӘ

2. Казан шәһәрендә өегезгә дә килеп яздырабыз. Моның өчен **562-50-12** яки **8-917-851 69 62** номерларына шалтыратып, заявка калдырырга кирәк

3. ИНТЕРНЕТ АША – ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ПОРТАЛЫНДА

Моның өчен кул астында интернетка тоташкан бераәр җайланма булуы гына кирәк

1. uslugi.tatarstan.ru сайтына кер;

2. «Подписка: газеты и журналы» дигән төймәгә бас;

3. Шәхси кабинетыңа кер;

4. «Шәһри Казан» (электрон каталогта – «Шахри Казан») газетасын сайла;

5. Адресыңны яз;

6. Дәүләт хезмәтләре порталы аша квитанцияне түлә.

Реклама

Тулырак мәгълүмат shahrikazan.com сайтында

Кыяр ашап сылуланабыз

Тиздән түтәлдән үзебез утырткан кыярларны өзеп ашар чак җитә. Ә бу – үз чиратында, организмны витаминнар белән баету белән берррәттән аны токсиннардан арындырырга һәм ябыгырга да мөмкинлек була дигән сүз.

Кыярда нәрсә булсын, ул бары судан гына тора, ди кайберәүләр. Әмма бу алай түгел. Чыннан да, кыярның 90 проценты судан тора. Тик анда организм өчен кирәкле C, A, B группасы витаминнары, шулай ук кальций, калий, тимер һәм магний кебек минераллар бар. Кыярның калориясе бик аз һәм шуңа күрә диета тотарга теләүчеләр өчен бик кулай ризык.

Әлбәттә, кыярлы диетада көне буе аны гына ашап торуны күздә тотылмый. Әлеге сусыл яшелчәне башка төр яшелчә-җимешләр белән катыштырып, фантазиягез кушканча, төрле салатлар ясап ашарга (иң мөһиме – көнлек рациондагы кыяр күләме 1,5 кг булсын!), ике йомырка яки майсыз эремчек кулланырга киңәш ителә. Составына әйтеп үтелгән әйберләр кергән ризыкларны көне буена биш тапкырга бүлеп ашау кирәк.

КЫЯРДАН БИК ҖИҢЕЛ ӘЗЕРЛӘНӘ ТОРГАН САЛАТ

2 кыяр
2 пешкән йомырка
100 г салат яфрагы
50 г руккола
3 сабак сельдерей
100 г әстерхан чикләвеге
1 теш сарымсак
1 лайм согы
150 мл натураль йогырт
Тәменә карап, тоз һәм борыч салып болгатырга.

Үз-үзеңне аңлыйсыңмы?

Кайчак язмыштан зарланырга яратабыз. Тик барлык уй-теләкләр тормышка ашсын дигәндә, үзебезнең ни теләгәнебезне кайчак аңлап кына бетермибез. Ә син үзеңне ни дәрәҗәдә аңлыйсың соң? Әйдә, түбәндәге тест ярдәмендә тикшереп карыйк.

1. Кайчак башта әйтәм, аннары ник әйттем инде дип үкенәм. ***(әйе – 1, юк – 5, сирәк – 3)***

2. Матур төш күргәндә аны истә калдырырга тырышам һәм аннары аны үземчә юрыйм. ***(әйе – 5, юк – 1, сирәк – 3)***

3. Кайчак кафега кергәч, меню́га 15 минутлап карап торам, ни кирәк икәнлеген тиз генә сайлый алмыйм. ***(әйе – 1, юк – 5, сирәк – 3)***

4. Туган көн алдыннан: «Сиңа нәрсә бүләк итик?» – дип сорaганда бик озак уйлыйм. Аннары монысы кирәгрәк, монысы булмаса да ярый, нәрсәгә миңа кирәкмәгән бүләк, дип сайланам. ***(әйе – 5, юк – 1, төрле вакытта төрлечә – 3)***

5. Кибеттә дустың белән йөрү яхшырак: читтән нәрсә килешә, нәрсә килешми икәнлеге яхшырак күренә дип уйлыйм. ***(әйе – 1, юк – 5, төрлечә була – 3)***

6. Әйе, минем кимчелекләрем күп, тик мин аларны бетерергә тырышам. ***(әйе – 5, юк – 1, исемә төшкәндә – 3)***

7. Кайбер кешеләргә юктан гына ачуым килә, ни өчен икәнлеген үзем дә аңламыйм. ***(әйе – 1, юк – 5, сирәк – 3)***

8. Үземнең биоритмымны бик яхшы беләм. Көчем ташып торган вакытта эшлим, ә «начарак вакыта» ял итәм яки бик үк мөһим булмаган эшләр белән шөгыльләнәм. ***(әйе – 5, юк – 1, төрлечә була – 3)***

9. Мин еш авырыйм. Әмма монда минем гаебем юк. Организмым шундый! ***(әйе – 1, юк – 5, периодлап – 3)***

НӘТИҖӘ

9-20: Син үзеңнең эш-гамәлләреңнән канәгать түгел. Һәр нәрсәне ничек булса, шулай булыр дип эшлисең. Үзеңне тыңла! Гадәттә, безне борчыган сорауларга җавапны читтән түгел, үзебездән табарга мөмкин.

21-33: Фикереңне туплап, күңелеңнән әзер булып эшкә тотынганда синең бар да яхшы килеп чыга. Тик синдәге тотрыксызлык, бераз ялкаулык һәм аклану уңышсызлыкка китерергә мөмкин. Тормышыңдагы кара полосаны акка әйләндерер өчен ихтыяр көчеңне ныгытырга, фикереңне туплап эш итәргә кирәк.

34-45: Син үзеңне биш бармагың кебек беләсең! Танышларың сиңа гаҗәеп интуиция кирәк вакытта нәрсә эшләргә кирәклеген «әйтеп» тора, ди. Син үзең әлеге уңыш серенең куктән төшмәгәнлеген, үз тырышлыгың белән бер дулкыннан икенче дулкынга күчә белү сәләтеннән килгәнлеген аңлыйсың.

Һәр хатын-кызның үзенең яраткан һәм еш куллана торган иннеге була. Әлеге гап-гади бизәнү әйбере хатын-кызның характеры турында сөйли икән.

Иннегең нинди – син шундый

Янып торган кызыл

Дәртле һәм амбициоз. Һәрчак команда белән эшләргә һәм ярдәмгә әзер.

Янып торган ал

Сезнең елмаюыгыз «йогышлы», бер мизгелдә сез теләсә кемне елмайтырга сәләтле. Яңа кешеләр белән тиз танышып, аралашып китәсез. Нинди эшкә тотынсагыз да илһамланып, бирелеп башкарасыз.

Җиләк төсе

Нинди дә булса киңәш кирәк булса, башкалар сезгә килә. Сез туры кеше, шул ук вакытта сүзегезне кешегә каты бәрелми генә җиткерә беләсез. Туганнарыгыз һәм якыннарыгыз сезнең ачык һәм ихлас булуыгызга соклана.

Шәмәхә

Тыныч характерлы хатын-кызлар. Чама хисен белә, холкы сыгылмалы, тугры.

Гигиена иннеге

Практик, гайбәт сатарга яратмый торган хатын-кызлар сөртә. Бушка вакыт уздырмый гына файдалы эшләр белән шөгыльләнергә ярата.

Ялтыравык иннек

Үзенә игътибар итүләрен ярата. Кичәләрдә беренче булып бии башлап, иң соңыннан гына туктый. Гламур буенча эксперт, поп-культура турында күп белә.

Тән төсендәге иннек

Бераз оялчан, әмма ачылып китсә, кешеләр шунда ук гашыйк була. Изге күңелле, тирә-юньдәгеләргә бәхет өләшүче.

Ачык ал

Башкалар өчен кайгыра белүче, амбицияле, йомшак һәм хисчән.

Слива төсе

Кыю, үз-үзенә ышанучан, башкалардан һәрчак аерылып торырга ярата.

«Кишер» кызыл

Позитив, күзгә ташланып тора. Табигатьне һәм яхшы ялны ярата. Тирә-юньдәгеләргә мәхәббәт белән карый һәм яхшы кәеф тарата.

ФОТОКИҢӘШ

Эч мускулларын дөрес ныгыту өчен түбәндәге күнегүләрне унар тапкыр ясарга кирәк.

Сәхифәне **Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА** әзерләде.

АБИТУРИЕНТ – 2017

Илгә эшчеләр кирәк

Казанның иң яхшы урта һөнәри белем бирә торган уку йортлары

Мәктәпләрдә соңгы кыңгырау чыңлады. Хәзер инде укучыларга имтиханнарын яхшы билгеләргә тапшырасы һәм булачак һөнәрләрен сайлыйсы гына кала. Ә ул арада инде ничәнче ел ил һәм республика җитәкчелеге эшче һөнәрләргә ихтыяҗ булу, аларның дәрәҗәсен күтәрү турында сөйли. Безнең укучыларыбыз арасында да юллар чатында торучы кешеләр барлыгын һәм «Мин дә мулла, син дә мулла, атка печән кем сала?» дигән гыйбарәне дә истә тотып, без Казанның иң яхшы урта һөнәри белем бирә торган уку йортларын барладык.

Казан медицина көллияте

Адресы: Мәүләтов урамы, 34 йорт
Телефон: 8(843) 229-23-24

Факультетлар	Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Дәвалау эше	фельдшер	55	67287	3 ел 10 ай (XI сыйныфтан соң гына)	IX сыйныфтан соң укыган кергәннәр өчен I курста гына бирелә
Акушерлык эше	акушер	25	64 429	2 ел 10 ай (XI сыйныфтан соң гына)	
Шәфкать туташы эше	Шәфкать туташы	60 260	53000	2 ел 10 ай (XI сыйныф) 3 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Лаборатор диагностика	Медицина-лаборатор техникы	25	61572	2 ел 10 ай (XI сыйныф)	
Фармация	Фармацевт (даруханәче)	25 60	53000	2 ел 10 ай (XI сыйныф) 3 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Ортопедик стоматология	Теш техникы		55 857	2 ел 10 ай (IX сыйныф)	

«Дәвалау эше», «Акушерлык эше», «Шәфкать туташы», «Ортопедик стоматология» бүлегенә укырга керү өчен көллиятнең үзендә сынау имтиханы үтәргә кирәк. Соңгысында рәсем ясый һәм әвәләп ясый белү мөһим. Документларның оригиналын 10 августка кадәр тапшырырга кирәк.

Казан педагогия көллияте

Адресы: Даурия урамы, 30 йорт
Телефон: 8(843) 298-85-18

Факультетлар / Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	IX-XI сыйныфтан соң укырга алыну мөмкинлеге	Белем алу вакыты	Тулай торак
Башлангыч сыйныфларда белем бирү	50	52 000 (көндезге бүлек) 26 000 (читтән торып уку бүлеге)	IX сыйныфтан соң укырга алалар, ә XI сыйныфтан соң читтән торып белем алу мөмкин	3 ел, 10 ай	бар
Мәктәпкәчә белем бирү (тәрбияче)	75				
Адаптив физик культура (Физкультура укытучысы)	25		IX сыйныфтан соң гына		
Гамәли информатика (Информатика укытучысы)	25				

«Мәктәпкәчә белем бирү», «Башлангыч сыйныфларда белем бирү», «Гамәли информатика» бүлекләренә документлар 15 августка кадәр кабул ителә. Адаптив физик культура юнәлешендә белем алырга теләүчеләр документларының оригиналын 10 августка кадәр тапшырырга тиеш. Бу юнәлештә абитуриент физик культура буенча өстәмә имтихан да тапшыра.

Казан энергетика көллияте

Адресы: Спартаков урамы, 111 йорт
Телефон: 8 (843) 202-30-90

Факультетлар / Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Җылылык электр станцияләре	50	Көндезге уку бүлеге – 44576 Читтән торып уку бүлеге – 22 288	IX сыйныфтан соң – 3 ел 10 ай XI сыйныфтан соң – 2 ел 10 ай	бар
Электр станцияләре, челтәре һәм системасы	25 (IX) 25 (XI)			
Электр энергиясе системасын автоматлаштыру һәм саклау	50 (IX) XI сыйныфтан соң түләп уку бүлеге генә эшли			
Электр энергиясе белән тәэмин ителеш	25			
Ремонт һәм хезмәт күрсәтү буенча электромонтерлаучы	25			
Электр челтәре һәм электр корылмалары электромонтажнигы	25			

Документларның оригиналын 15 августка кадәр тапшырырга кирәк. Бюджет урыннары калса, уку йорты абитуриентларны 25 ноябрьгә кадәр кабул итә.

Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумы (КАТТ)

Адресы: Карбышев урамы, 64 йорт
Телефон: 8(843) 229-48-62

Факультетлар / Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Автомобильгә техник ярдәм күрсәтү һәм ремонт	75 (IX) 25 (XI)	Укыту бары тик бюджет формасында гына	2 ел 10 ай (XI сыйныф) 3 ел 10 ай (IX сыйныф)	Бар
Йөк күтәрүче, төзелеш машиналарын һәм корылмаларны куллану	25 (IX)		3 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Кучерүләрне оештыру һәм транспорт-та идарә	50 (IX)			
Транспорт электр җиһазларын һәм автоматиканы куллану	25 (IX)			
Компьютер системаларында программалаштыру	25 (IX)			
Электр белән тәэмин ителеш	25 (IX)			
Автомеханик	25 (IX)		2 ел 10 ай	
Локомотив машинисты	25 (IX)		3 ел 10 ай	

Автомеханик белгечлегенә укучы машина йөртү буенча B,C категориясендәге таныклыкны түләүсез укып ала.

Кирәк булачак документлар исемлеге

- ✓ көллияткә/техникумга кабул итүләрен сорап, директор исеменә гариза;
- ✓ белем алу турында документ (оригинал һәм расланган копия);
- ✓ 3х4 зурлыктагы 4-6 фотосурәт;
- ✓ паспорт (оригинал һәм расланган копия);
- ✓ сәламәтлек турында белешмә (086-у формасындагы медицина белешмәсе, прививкалар буенча сертификат);
- ✓ СНИЛС күчермәсе;
- ✓ ИНН күчермәсе;
- ✓ мәктәптән характеристика;
- ✓ 18 яше тулмаган абитуриентларга әтисенең яки әнисенең паспортының 2, 3нче битләре күчермәсе кирәк.

Казан радиомеханика көллияте

Адресы: Кызыл Пожарник урамы, 1а йорт
Телефон: 8 (843) 297-00-62

Факультетлар / Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Радиоэлектрон аппаратура монтажчысы	25		2 ел 10 ай	юк
Токарь-универсал	20		2 ел 10 ай	
Радиоаппаратын төзү (радиотехник)	25	21000	3 ел 10 ай	
Электрон приборлар һәм җайланмалар (техник)	25	21000	3 ел 10 ай	
Машина төзелеше технологиясе	25	19000	3 ел 10 ай	
Техник көйләү һәм сыйфат белән идарә итү	Түләп уку бүлеге	25 000 (18-25 кешелек төркем) 29 000 (10-17 кешелек төркем)	3 ел 10 ай	
Социаль-мәдәни эшчәнлек (менеджер)	Түләп уку бүлеге	25000	3 ел 10 ай	

Документлары 15 августка кадәр кабул итәләр. Бюджет урыннары калса, кабул итү комиссиясе 1 октябрьгә кадәр эшли.

Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте

Адресы: Копылов урамы, 2Б йорт
Телефон: 8(843) 210-17-23

Факультетлар / Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Машина төзелеше технологиясе (белгеч, техник)	50 (IX сыйныф)	Төркемдә 15 кеше җыелса, түләүле укып була. Уку бәясе 40 меңнән алып	3 ел 10 ай (IX сыйныф) 2 ел 10 ай (XI сыйныф)	Юк
Очу аппаратлары җитештерү	50 (IX)			
Авиация двигательләрен җитештерүче	25 (IX)			
Технологик процесслар һәм җитештерүне автоматлаштыру	25 (IX)			
Мәгълүмати системалар	25 (IX)			
Компьютер системасы һәм комплексы	25 (IX)		2 ел 5 ай (IX сыйныфтан соң) 10 ай (XI сыйныфтан соң)	
Эретеп ябыштыручы	25			
Станокчы	25			
Токарь-универсал	25			
Фрезеровкалаучы-универсал	25		3 ел 5 ай (IX сыйныфтан соң) 1 ел 10 ай (XI сыйныфтан соң)	
Авиация техникасын җыючы слесарь	25			
Авиация техникасын электр монтажлаучы	25			
Ремонт эшләре буенча электромонтер һәм электр корылмасына хезмәт күрсәтү	25		2 ел 5 ай (IX сыйныфтан соң) 10 ай (XI сыйныф базасында)	
Цифрлы мәгълүматны эшкәртүче оста	25			

Казан технология һәм дизайн көллияте

Адресы: Ш.Мәрҗани урамы, 26 йорт
Телефон: 8 (843) 293-00-84

Факультетлар / Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Күн һәм мех технологиясе	25 (IX сыйныф)	42066	3 ел 10 ай	бар
Мех эшләнмәләре технологиясен төзү, модельләштерү	25 (IX сыйныф)	39557	3 ел 10 ай	
Күн эшләнмәләре технологиясен төзү, модельләштерү	25 (IX сыйныф)	39 557,00	3 ел 10 ай	
Тукыма эшләнмәләре технологиясе	25 (IX сыйныф)	39557	3 ел 10 ай	
Туку эшләнмәләре технологиясен төзү, модельләштерү	25 (IX сыйныф) 25 (XI сыйныф)	39557	2 ел 10 ай 3 ел 10 ай	
Товар белгече (товаровед) һәм кулланучы товарларның сыйфатын билгеләүче эксперт	25 (IX сыйныф) 25 (XI сыйныф)	42246	2 ел 10 ай 1 ел 10 ай	
Мәгълүмати системалар техникы	25 (IX сыйныф)	43095	3 ел 10 ай	

Мех һәм күн, туку эшләнмәләре технологиясен төзү, модельләштерү юнәлешләрендә иҗади имтихан тапшырырга кирәк. Бюджет бүлегендә буш урыннар булса, документлар 25 ноябрьгә кадәр кабул ителә.

Укырга кергәндә, «Диплом» дигән катыргы алырга гына кызыкмагыз. Белемегез киләчәктә эшегездә дә кулланырлык булсын. 10-20 елдан соң нинди һөнәрләр аеруча популяр булачак? Бу сорауга җавапны «Сколково» бизнес-мәктәбе да эзләгән. Алар 2016 елда «Яңа һөнәрләр атласы» дигән китап та чыгарган.

Киләчәк һөнәрләре

Инженер-композитчы. Җитештерү өчен 3Д-басма, робот техникасын кулланып композит материаллар әзерли.

IT-генетик. Нәселдән килүче авыруларны генны программалаштырып дәвалый.

IT-табиб. Дәвалаучы һәм диагноз куючы җиһазлар өчен программалар төзи.

Эколог-урбанист. Яңа экологик чиста шәһәрләр проектлаштыра, төзи.

«Акыллы юллар» салучы. Андый юллар юлның халәтен күзәтеп торучы датчиклар белән салына. Үзенең юл кагыйдәләре билгеләре, видеокамералары булачак.

«Акыллы йорт» төзүче. Компьютер программасына көйләнгән йортлар сала.

Интеллектуаль белемне санаучы. Материаль булмаган активларны (идея, яңа ачышлар, бизнес-модельләре) бәяләүче.

Краудфандинг (берничә кеше финанслау) һәм краудинвестинг (берничә инвестор финанслау) платформалар менеджеры. Краудфандинг платформалар эшен көйли, проектларны бәяли, проект авторы белән акча кертүче инвесторлар арасында булган конфликтларны киметә.

Космик туризм менеджеры. Космос киңлекләренә, айга туристлар җибәрү белән шөгыльләнүче.

Молекуляр диетолог. Кешенең ген анализы һәм ризыкның молекуляр составына карап шәхси диета төзүче.

Генетик-консультант. Генетик анализ буенча белгеч. Ген дәрәҗәсендә кешенең сәламәтлеген тикшерә.

Сити-фермер. Күпкатлы йортлар түбәсендә, диварларында яшелчә, җиләк-җимеш үстерүче.

Визуаль дөнья дизайнеры. Үз табигате, архитектурасы булган визуаль дөньялар төзүче, алар буйлап сәяхәтләр үткәрүче.

Сәламәт картлык белгече. Олы яшьтәгеләрнең туклануын, физик күнегүләрен системага салучы. Көн тәртибе төзүче.

Прораб-вотчер. Бина төзүне цифрлы проектлар ярдәмендә көйли, хисаплап чыгара.

Экопроповедник (экологияне саклауга өндәүче). Балаларга һәм олыларга экологик дәресләр бирә. Экологик яшәү рәвешен пропагандалый.

Экологик катастрофаларны булдырмаучы, аларны бетерүче белгеч.

Космобиолог һәм космогеолог. Космобиолог космос киңлекләрендә тере организмнарның үз-үзен тотышын тикшерә, үзгәрүләрен өйрәнә. Орбитадагы станцияләрдә, айдагы базаларда экологик система булдыра. Ә космогеолог айдагы һәм астероидлардагы файдалы казылмаларны эзли.

Интернет челтәре юристы. Интернет кулланучылар өчен законнар булдыра, виртуаль милекне саклый.

Саннар лингвисты. Компьютер телен тәрҗемә итүче. Кеше белән компьютер аралашуын җайга салучы.

ЮГАЛУЧЫ ҺӨНӘРЛӘР

Бүген күп кенә һөнәрләргә юкка чыгу куркынычы да яный. Берничә дистә елдан почта хезмәте, кондуктор, журналист, хисапчы, икътисадчы, архитектор, тегүче, китапханәче, кассир, официант кебек һөнәр ияләрен күрмәячәкбез, ди белгечләр. Аларны замана технологияләре алыштырачак.

Казан төзелеш көллияте

Адресы: Липатов урамы, 25 йорт
Телефон: 8 (843) 234-24-22

Факультетлар / Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Биналарны һәм корылмаларны төзү һәм куллану	25	41000-48000	IX сыйныфтан соң: 3 ел 10 ай (техник) 4 ел 10 ай (баш техник) IX сыйныфтан соң: 2 ел 10 ай (техник) 3 ел 10 ай (баш техник)	бар
Металл булмаган төзелеш җиһазларын җитештерү	20		IX сыйныфтан соң: 3 ел 10 ай (техник)	
Автомобиль юллары һәм аэродромнар төзү, куллану	20		IX сыйныфтан соң: 3 ел 10 ай (техник)	
Шәһәр төзелешендә мәгълүмати системалар	20		IX сыйныфтан соң: 3 ел 10 ай (техник) XI сыйныфтан соң: 2 ел 10 ай (техник)	
Икътисад һәм хисапчы	-		IX сыйныфтан соң: 2 ел 10 ай (хисапчы); XI сыйныфтан соң: 2 ел 10 ай (налог салу өлкәсен тирәнтен өйрәнгән хисапчы)	
Җир иминиятләштерү эшләре	20		IX сыйныфтан соң: 2 ел 10 ай (белгеч)	
Бизәү төзелеш эшләре мастеры (штукатур-маляр)	25		IX сыйныфтан соң: 2 ел 5 ай; XI сыйныфтан соң: 10 ай	
Гомумтөзелеш эшләре мастеры (ташчы, эретеп ябыштыручы һ.б.)	50			
Коры төзелеш эшләре мастеры (штукатур, плитә ябыштыручы һ.б.)	20			
Агач остасы, паркет җәюче	20			
Эретеп ябыштыручы	25			
Электрон җыю һәм версткага салу операторы	-			
Сәркатип	-		XI сыйныфтан соң: 10 ай	
Ремонт эшләре буенча электромонтер, электр җиһазларына хезмәт күрсәтү	20		IX сыйныфтан соң: 2 ел 5 ай; XI сыйныфтан соң: 10 ай	

Казан мәгълүмати технологияләр һәм элемтә техникумы

Адресы: Сәетгалиев урамы, 3а йорт
Телефон: 8(843) 272-13-61

Факультетлар	Белгечлек	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Электроника, радиотехника һәм элемтә системасы	Хәрәкәт итүче объектларга элемтә кертү (средства связи с подвижными объектами)	25	42000	3 ел 5 ай (IX сыйныфтан соң) XI сыйныф белеме белән укырга II курска алалар	бар
	Күпканаллы телекоммуникация системалары	25+ 15 (читтән торып уку)			
	Элемтә челтәре һәм коммуникация системасы	25 + 15 (читтән торып уку)			
	Почта элемтәсе	25			
Информатика һәм хисаплаучы техника	Компьютер системасы һәм комплексы	25 (IX сыйныфтан соң) 25 (XI сыйныфтан соң)	47000	IX сыйныфтан соң – 4 ел XI сыйныф белеме белән II курска алалар	
	Компьютер челтәре	25			
	Компьютер челтәрендә программалаштыру	25			
Мәгълүмати куркынычсызлык	Автоматлаштырылган системаларда мәгълүмати куркынычсызлык	25			

Документларның оригиналын 15 август кичке сәгать бишкә кадәр тапшырырга кирәк.

Россия буенча уртача хезмәт хакы (сумнарда)

ЧПУ станокларында фрезер эшләре – **43 000**
ЧПУ станокларында токарь эшләре – **44 000**
Эретеп ябыштыручы – **51 000**
Авиацион техникага хезмәт күрсәтү – **38 000**
механик – **40 000**
пешекче – **34 000**
шәфкать туташы – **19000-23000**

Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш көллияте

Адресы: Энергетиклар урамы, 10 йорт
Телефон: 8(843) 564-26-41

Факультетлар	Бюджет урыннары	Түләп уку бәясе	Белем алу вакыты	Тулай торак
Күпфатирлы йортлар белән идарә итү, хезмәт күрсәтү һәм куллану	25	42066	3 ел 10 ай (IX сыйныф)	Бар
Архитектор	25	43095	3 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Сантехника корылмаларын монтажлау һәм куллану, вентиляциягә кондиционер кую	25	42066	3 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Биналарны һәм корылмаларны төзү, куллану	60 25	49593	3 ел 10 ай (IX сыйныф) 2 ел 10 ай (XI сыйныф)	
Йорт һәм коммуналь хуҗалык сервисы	20	53132	2 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Социаль хезмәт	25	46772	3 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Икътисад һәм бухгалтер учеты	25	45110	2 ел 10 ай (IX-XI сыйныф) (IX сыйныфлар өчен түләүле бүлек кенә)	
Коммерция (сату эшләре буенча менеджер)	25	53132	2 ел 10 ай (IX-XI сыйныф) (XI сыйныфлар өчен түләүле бүлек кенә)	
Финансчы	Түләүле бүлек кенә	38077	1 ел 10 ай (IX сыйныф)	
Иминиятләштерү эше	Түләүле бүлек кенә	40586	2 ел 10 ай (IX сыйныф)	

Көндезге уку бүлегенә документлар 1 июнь-14 август аралыгында кабул ителә.

Илдар Мөхәммәтов, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары:

– Соңгы елларда бездә техник белемнәргә зур игътибар бирелә. Өстәмә белем системасында 13 проценттан артык бала техник юнәлештә шөгыльләнә. Россия буенча республика – алдынгы урында. Һөнәрләр гел алышынып тора. Әйтик, социаль челтәрләрдә эшләүче кешеләр барлыкка килде. Минемчә, якын киләчәктә интернет челтәре, социаль-медиа юнәлеше алдынгы рәттә булыр. Эшче һөнәрләр дә популяр булыр дип өметләнәбез. 2019 елда да Казанда тикмәгә генә «Worldskills» буенча дөнья чемпионаты оештырмыйбыз. Аның максаты – эшче һөнәрләрен үстерү. «Juniorskills» хәрәкәте дә бар бит әле. Ул балаларны мәктәптән үк эшче һөнәрләренә өйрәтә. Бу бик дөрес хәрәкәт.

Иван Филатов, Татарстан Республикасының ел укытучысы (2016 ел):

– «Нинди һөнәрләр кирәк булыр икән?» дигән сорауны Россия Президенты Владимир Путинга да бирдем. Ул озак җавап бирми торды, уйлады. Аннан ун елдан космос, медицина, нанотехнологияләр, техник юнәлештә булган һөнәрләр популяр булачак диде. Кызганыч, ул исемлеккә гуманитар юнәлештә белем алучылар кермәде. Ләкин мин укытучылар, табиблар да һәрвакыт сорала торган һөнәр булыр дип уйлыйм. IT заманында программистлык та абитуриентлар өчен бик перспективалы юнәлеш.

Сәхифәне **Алисә САБИРОВА** әзерләде.

ЯЗМЫШНЫ ҖИҢҮ

Татарстан кызына уникаль протезлар куелды

Шушы көннәрдә Азнакай кызы Гөлназ Насыйбуллинага Мәскәү табиблары уникаль протез куйдылар. Бер ел дәвамында сул кулы белән генә эшләргә мәҗбүр булган туташ өчен моннан соң яңа тормыш башлана.

Зөһрә САДЫЙКОВА

«ЕЛАМАДЫМ ДА»

Гөлназ – КФУның Чаллыдагы филиалы студенты. Шушы шәһәрнең икмәк пешерү заводында эшләгәндә 2016 елның 12 маенда ул уң кулының бармакларын өздергән. Гөлназ әйтүенчә, әлеге предприятие хезмәткәрләре куркынычсызлык кагыйдәләре һәм эш режимнары идеаль булмаган шартларда эшләгән. Аларга хәтта көн белән төнне ялгап, берничә смена рәттән эшләргә туры килгән. Бәхетсезлек очрагы килеп чыккан көнне дә Гөлназ: «Тыгыз эш графигы булу сәбәпле, бик арыган идем», – ди. Җитмәсә, кыз эшли торган штамповкалау машинасының да капкачы күптәннән булмаган. Дөрес, аның әйтүенчә, предприятие эшчеләре моңа җайлашкан да булган инде – махсус көрәк кулланганнар, анысы да сынып чыккач, кул белән эшләргә туры килгән.

– Ул көн бүгенгедәй күз алдымда. Кулым камыр белән бергә машина валлары арасына эләккәч, авыртудан кычкырып җибәрдем. Аннан соң урамга алып чыктылар. Әмма көчле авыртудан шок кичерсәм дә, аңымны җуймадым, хәтта еламадым да, – дип искә ала кыз тормышын үзгәрткән вакыйга турында.

Гөлназның әти-әнисе Азнакай районының Әгерҗе авылында яши.

– Сәгать кичке сигезләрдә Гөлназ: «Әни, мин җәрәхәтләндем», – дип шалтыратты. Аның шундый гадәте бар: шок хәлендә ул еламый, киресенчә, туктамыйча көлә. Монда да шулай булды. Бераздан кызымның телефонын кабат җыйдым. Анда инде дусты Алсу алды. «Берни дә яшермичә, дөресен генә әйт, Гөлназның хәле ничек?» – дип сорагач, ул: «Аның кул бармаклары юк», – диде. Шуннан соң без ирем белән Чаллыга киттек. Юл буе еладым. Без килеп җиткәндә, операция ясаганнар иде инде, – дип, авыр истәлекләре белән уртаклашты Суфия апа.

Операция ясаучы табиб Дмитрий Шаламонов Гөлназның уң кулының дүрт бармагын кисә, ә кызның үтенече белән, баш бармагын калдыралар, шуннан соң Казанда Илсур Муллин кабат операция ясый. Аннан соң Гөлназ өчен тернәкләнү чоры башлана. Сул кул белән язарга, ашарга әзерләргә, вак-төяк эшләр эшләргә өйрәнгәнче никадәр күз яше, түшенкелеккә бирелүләр, суд юлларын таптау – берсе дә читләтеп узмаган.

– Шушы вакыйга тормышка карашымны үзгәртте, яңашәмдәгеләрнең кемнең кем икәнлекләрен аңладым. Минем белән бергә булган әти-әниемә, туганнарыма, дусларыма рәхмәт, – ди 23 яшьлек кыз.

Суд Насыйбуллиннарга 200 мең сум компенсация түләргә, дигән карар чыгара. Гөлназ әйтүенчә, дарууларга, адвокатка һәм башка чыгымнарга бер ел эчендә 300 мең сумнан артыграк акча тотылган. Мәскәүнең «Моторика» компаниясе эшләгән хәрәкәтләнә торган «Киби» протезы өчен исә гаилә 99 меңгә якын акча түләгән.

– Моңа кадәр дә минем берничә төрле протез киеп караганым булды, әмма алар хәрәкәтләнмәгәч, уңайсыз иде. Ә болары ошады, төсе дә үзем теләгәнчә. Һиһаять, уң кулыма сумка тота, «бармак»ларымны бөгә алуыма бик шатмын, – диде Гөлназ, ясалма кул чукларын киеп караганнан соң.

«БУ – РОССИЯДӘ БЕРЕНЧЕ ТӘҖРИБӘ»

Әлеге протезлар турында бәләгә юлыккан кызга дусты әйтә. Хәрәкәтләнә торган кул чуклары һәм беләк протезлары эшләү буенча махсуслашкан «Моторика» компаниясе белән элемтәгә чыккач, алар Гөлназга ярдәм итәргә алына һәм үзләре үк Казанга килергә әзер булулары турында белдерә. Тартыла торган протезлар юнәлеше җитәкчесе Данил Емелин әйтүенчә, ике ел эчендә алар, 150 балага ярдәм итеп, дөнья базарына чыгу бәхетенә ирешкән. Шунысы да мөһим: килешүгә кул куелып, протез авыруга барып җиткәнче нибары 10-15 көн уза.

– Бу – Россиядә беренче тәҗрибә, хәрәкәтләнә торган протезлар хәтта дөньяда да юк диярлек. Без заказларны Җир шарының теләсә кайсы почмагыннан кабул итәбез. Мөрәҗәгать итүчеләр кулларын өч төрле ракурстан (линейка янәшәсендә) фотога һәм видеога төшереп җибәрә. Шуннан соң без үлчәмнәрен алабыз һәм махсус программада протезның күләмле моделен ясыйбыз. Аннан соң имгәнгән кулга туры китерелгән индивидуаль модель принтер аша чыгарыла, – дип аңлатты Данил безгә.

Мондый протезлар олыларга да, балаларга да ясала. Кул чуклары өч яшьтән өлкәнрәк балаларга куелса, беләкнекен ике яшьтән зурракларга ясыйлар. Дөрес, шулай да һәр протез индивидуаль эшләнелә, ди Данил. Шуңа күрә аны кечерәк яшьтәге сабыйларга да ясарга мөмкин икән. Балаларга ул тулы юридик һәм психологик ярдәм белән бергә бер елга эшләнә. Аның төсен һәм дизайнын авыру үзе сайлый. Кул чукларының бәясе 100 меңгә кадәр булса, беләкнеке – 150 мең сум. Әмма, Данил әйтүенчә, пациентлар, протез сатып алган акчаны Социаль иминиятләштерү фонды аша кире кайтара ала. Шуңа күрә әлеге компания ясалма кулның бәясен дәүләт кайтарып бирергә тиешле суммадан арттырмаска тырыша.

Татьяна БАХТИГОЗИНА,
«Моторика» проекты җитәкчесе:

– Россия законнары буенча, шәхси тернәкләндерү программасы булган инвалидларга тернәкләндерүнең техник чараларын һәм протез-ортопедик эшләнмәләрне бушлай алу мөмкинлегенә каралган. Әгәр инвалидка бушлай тәкъдим ителгән тернәкләндерү чарасы тегеяки бу сәбәп буенча туры килмәсә, ул шәхси тернәкләндерү программасында күрсәтелгән чараны үзе сатып алырга мөмкин. Ә инде соңыннан аның акчасын Социаль иминиятләштерү фонды аша тулысы белән яки өлешчә кайтарта алачак.

ПОЧТАДАН

Суфия белән Кәбир мәхәббәте



Җәй җиттеме, Чабаксарда яшәүче туганнарыбызга – әтиемнең Суфия исемле апасына балаларым белән кунакка бара идек. Соңгы баруымда Суфия апа: «Дога кылырсың, укыган саен, безне искә алырсың», – дип, кара тышлы саргаеп беткән бер дәфтәр сузды. Баксаң, бу тормыш иптәше Кәрим җизнинең аңа яшьлектә бүләк иткән сөю шигырьләре тупланган көндәлеге икән. Күңеле сизгәндерме, Суфия апам шул күрешүдән соң озак тормады, 90 яшенә җитеп, бакыйлыкка күчте. Аны озак еллар бергә яшәгән ире янына – Чабаксарның татар зиратына җирләделәр.

Хәзер туганнарымның истәлеге – мәхәббәт шигырьләре тупланган дәфтәр миндә саклана. Көндәлекнең беренче битенә үк «Май. 1945 ел» диелгән. Ул чакта 18 яшьлек Суфия апа кибетче булган, Кәбир абый исә Яшел Үзән шәһәрендәге заводта эшләгән. Шигырьләр латин графикасы һәм кириллица белән язылган.

Суфия апаны белгән кешеләр аны бик чибәр булган дип искә алалар. Хәтта ялкынланып торган битләренә карап: «Чия сөрттеңме әллә?» – дип тә шаярта торган булганнар. Кыз бик матур җырлаган, кул эшләренә оста булган. Аның чиккән сөлге-кашагалары бүген дә саклана.

Кәбир абый апамны бер күрүдә үк ошата. Дәфтәрдәге шигырьләрендә дә шул хакта әйтелгән:

«Чалт аяз төн.
Һава чиксез матур,
Төн тынлыгын боза җил генә.
Зәңгәр күктә күпме
йолдыз балкый,
Йөрәгемдә, бәгырем, син генә».

Кереш өлештә үк Кәрим абый, Суфия апага мөрәҗәгать итеп: «Үтенәм, бу шигырьләрне укыганда яр сөйгәнне, сөймәгәнне, сөенең нәрсә икәнен аңлап укы. Суфия, чын күңел биреп укы», – дигән. Ахырда бу дәфтәрне сөйгәне Суфиягә 1945 елның 31 декабрендә Яңа ел бүләге итеп бирүе турында да әйткән. Ел дәвамында тупланган шигырьләрдә – күңел кичерешләре, күпме сагыну, мәхәббәт хисләре.

Нинди кадерле бүләк. Бүген болай мәхәббәт аңлатучылар, мондый шигырьләр язучыларга гаҗәпләнеп карарлар иде, мөгаен. Ә бу язулар ихлас күңелдән булган.

Суфия апам белән Кәбир җизни язмышларын уртак итә. 50 елдан артык парлы гомер кичерәләр. Бик бәхетле яшиләр. Дүрт ул тәрбияләп үстерәләр. Хамиз, Фирдус, игезәк балалар Илдус белән Илгиз – әти-әнисенең дәвамчылары. Бу кара тышлы мәхәббәт шигырьләре дәфтәре Суфия апа белән Кәбир абыйның һәрчак үзләре белән булды. Мин дә бу истәлекле ядкәрне игезәк уллары Илдус белән Илгиз абыйларга тапшырырга булдым әле.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Казан.

Ураза тоту кагыйдәләре

Ураза башланырга санаулы көннәр калып бара. Әлеге фарыз гамәлне үтәүдә бәндәләргә нинди вазифалар йөкләнә? Ураза тоткан кешегә нәрсәгә игътибарлы булырга кирәк? «Гаилә» мәчете имам хатибы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин белән без шулар турында сөйләштек.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Аллаһы Тәгалә бер хәдисендә «Ураза ул Минем өчен һәм аңа әҗер-савабын Үзем бирәм» дигән. Аллаһның уразаны Үзе өчен дип әйтүе – бу гыйбадәтнең дәрәҗәсен күтәрү. Шушы сүз белән Ул уразаның башка гыйбадәтләрдән өстен булуын күрсәтә. Адәм баласының һәр гамәле үзе өчен. Һәр изгелеккә ун савап бирелә, хәтта ул 700гә кадәр арттырыла. Аллаһы Тәгалә, бу айда тагын да юмартлыгын күрсәтеп, уразаның әҗер-савабын хисапсыз бирә. Шуңа да Ул, әҗер-савабын үзем бирәм, ди. Рамазан аенда ураза тотарга, гыйбадәтләребезне арттырырга, иманыбызны ныгытырга ашыгыйк. Ураза җәйге озын көннәргә туры килә, шуны авырсынмыйча, сабырлык күрсәтсәк, тәкъвалыкка ирешербез.

– Халык арасында: «Рамазанның башында өч көн, уртасында өч көн һәм ахырында өч көн ураза тоту да җитә», – дигән сүз йөри. Моңа аңлатма бирсәгез иде.

– Мөфтиебез Камил хәзрәт Сәмигуллин әйтмешли, беренче ун көндә, анның уртадагы ун көндә, аннан ахырында ун көт тотарга кирәк. Уразаны калдырырга ярамый, ул – фарыз гамәл. Баштагы өч көндә генә авыр, аннары организм ияләшә, җайлаша. Һәрбер гамәл нияттән тора. Ураза тота алырмынмы дип шикләнә икән, ул аның барып чыкмый. Сәламәтлек, көч-куәт бирсәң иде дип сорасаң, катгый ният кылсаң, Аллаһы Тәгалә сиңа ярдәм итми калмый.

– Хәзрәт, сәхәрне бик иртә, ә ифтарны соң ашарга туры килә. Сәхәр ашамыйча гына уразага керергә ярыймы?

– Бу сорауны безгә еш бирәләр. Сәхәр ашамыйча гына уразага керергә ярый, әмма йокларга ятканда, уразага керәм дип, ният кылырга кирәк. Пәйгамбәребезнең, сәхәр ризыгын ашагыз, чөнки бу вакытта бәрәкәт бар, дигән сүзе бар. Сәхәрне ашасак, хәерлерәк була.

– Намаз укымый торган кешегә ураза тоту дөрес буламы?

– Халык арасында бу шулай ук актуаль сорау. Аллаһның рәхмәте белән, дингә кайта башладык. Намазга басучыларның саны артты. Ислам дине биш нигездән тора. Аллаһы Тәгаләне тану һәм аның берлегенә ышану, намаз уку, зәкят түләү, ураза тоту, хаҗ кылу. Без шушы биш фарызны үтәргә тиеш. Намаз өчен аерым, ураза өчен аерым җавап бирәсе була. Намаз укыганга да, ураза тотканга да, зәкят биргәнгә дә, хаҗга барганга да аерым савап языла. Ураза тотарга теләгән кеше аны тотсын, иншаллаһ, акрынлап намазына да басар.

– Былтыргыдан калган көннәр өчен уразасын тотып бетерә алмаучы нишли?

– Бурычлары калганнар башта бу уразаны, аннары былтыргыдан калган көннәре өчен тотарга тиеш.

– Ураза тотучыга тәравих намазына йөрү мәҗбүриме?

– Тәравих намазын уку – сөннәт. Аның өчен зур савап вәгъдә ителә. Тәравих намазын укыр өчен мәчеткә барырга хәлең булмыйча өйдә калсаң, гөнаһысы юк.

– Уразага керә алмаучы фидия сәдакасын ураза тотучыга гына бирергә тиешме?

– Мескен-фәкыйрьләргә дә бирергә ярый. Ул бер көн өчен бер мескенне ашатырга яки аңа 200 сум акча йә булмаса шул суммага алынган ризык бирергә тиеш. Быел фидия сәдакасының күләме 200 сум итеп билгеләнде.

– Ураза тотарга сәламәтлеге булмаган, пенсиягә аз булган өлкән кешеләргә нишләргә? Көн саен 200 сум бирә башласаң, бер айга 6 мең сум килеп чыга бит...

– Аллаһы Тәгалә безгә авырлыкны теләми. Ул һичкемне көче җитмәгән эш белән көчләмәс, мәгәр көче җиткән эш бирер. Нияте изгедә булып, ураза тотучыны бер хөрмә яки бер йотым су белән булса да авыз ачтырсагыз, сез шулай ук әҗер алырсыз, Аллаһ аны һичшиксез кабул итәр.

– Фидияне ураза тотарга сәламәтлеге, мөмкинлеге булмаган кеше генә бирә ала дип беләм.

– Әлбәттә, шулай. Күпләр, фидия сәдакасын бирергә кирәк дигәч, алдана. Сәдака бирәм дә минем өстемнән төшә дип уйлый. Коне буе ач торып җафаланганчы, сәдакасын гына бирeп котылам, диләр. Ураза тотарга мөмкинлеге булып та аны тотмаучы фидияне бирә алмый, аның өстеннән уразасы төшми. Сәламәтлеге булган бөтен кеше дә ураза тотарга тиеш. Рамазан аенда чирләп китсәң, аны башка айларда тот.

– Сәфәрдәге кешеләр ураза тотарга тиешме?

– Өеңнән йөз чакрым ераклыкка китсәң, тоту мәҗбүри түгел. Юл авыр булмаса, тотсаң да ярый.

– Уразалы кешегә мунча керергә рөхсәт ителәме?

– Җиңелчә юынып чыкса ярый. Озаклап тирләп утырса хәле китәргә, уразасын тотып бетерергә көче җитмәскә мөмкин Хәл керсен өчен, аякларын салкын суга тыгып утырырга, салкынча су белән коенып чыгарга ярый.

– Уразада чәч кистерергә ярыймы?

– Ярый, ул уразаны бозмый.

– Уразада булып, ялгышкына ризык кабып куйсаң нишләргә?

– Уразаңны дәвам итәсең. Бу очракта ураза бозылмый.

– Рамазан аенда башка айларга караганда сәдакага әҗер-савап күбрәк бирелә икән...

– Сәдака гына түгел, изге гамәлләрнең дә савабы күбрәк языла.

– Кадер кичәсен рамазанның ахыргы ун көненнән эзләргә кирәк, диләр. Быел ул кайсы көнгә туры килер икән?

– 21 июньнән 22сенә каршы төндә булыр дип уйлыйбыз.

ИМАНЛЫ СҮЗ

Сәхәр ашап бетергәч, уразага ният кылына. *«Иләһи ният кылдым, Раббым, Үзеңнең ризалыгың өчен Рамазан уразасын тотмакка, таң беленгәннән алып кояш баеганга кадәр».*

Гарәпчәсе. *«Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамәдаанә минәл-фәҗри иләл-мәгърибИ халисан лилләһи тәгааләә».*

